

Рәфит Мөхәмәтшин

# Көзге җимешләрем

(шигырьләр)

Рәфит
Мөхәмәтшин



# Көзге җимешләрем

(шигырьләр)

2017 ел.



Мөхәмәтшин Рәфит Нурихан улы Башкортстанның Яңавыл районының Ижбулды авылында туган. Тормыш иптәше Хәсинә Зайнулла кызы белән 54 ел гомер итеп дүрт бала тәрбияләп үстерделәр.

Ул күп еллар мәдәният йорты директоры вазифасында эшләде. Аның күңелендә шигъри юллар туган һәм аларның шушы өлеше бу китапка тупланган.

## БЕЗ ЯШЬ ЧАКТА

*01.03.2012 ел.*

Чабатаны катлый-катлый
Бии идек клубта.
Хәзергеләр өйдә ята, телевизор почмакта,
Бию көе чыккан чакта селкенә караватта.

Карлар эреп, җире чыкса,
Менә идек хан-тауга.
Ач-ялангач булсак та без,
Чыгармый идек гауга.

Спектакльләр куярга,
Бардык төрле якларга.
Кайталсак та, хәйлә табып,
Куныпкалдык авылда.

Кунган җирдә урын да юк,
Өстә дә тун, аста да.
Тагын кайчан барабыз дип
Завклубка, зар чыга.

Әй, замана, замана,
Белмибез кадерләрен.
Кайберәүләр туганнарының
Белми шул каберләрен.

Үткәннәр кире кайтмасын,
Кермәсен төшләргә дә.
Киләчәк матур булсын дип,
Кирәк шул эшләргә дә.

Безнең заман очсыз иде,
Ач-ялангач яшәдек.
Хәзер чүплектә дә байлык,
Тагын мең ел яшәрлек.

Хәзер киемнәр дә чутсыз,
Ашамлык артып кала.
Басуларда чуп-чар үсә,
Әйтерсең булган дала.

Кайбер илдә бер телемгә,
Зар, интизар йөриләр.
Киләчәк үзе күрсәтер,
Алар монда килерләр.

Ачлык-ялангачлык теләп,
Артист чыга сәхнәгә.
Кендек ачык, бот ялангач,
Юк шул каплар нәрсә дә.

Ашат мине, мин ач, - дип,
Кендек ачкан авызын.
Безнең инәй кечерткәне,
Каплар иде авызын.

Бот ялангач булды шулай,
Тирес-кирпеч сукканда.
Түгел инде, билет сатып,
Сәхнәләргә чыкканда.

## АВЫЛЫМ ЧИШМӘЛӘРЕ

Шушы язманы укыдым,
Өмет дигән гәзиттән.
Үзең хезмәт салып эчкән,
Сукайларга ни җитә.

Шушы язма безнең өчен,
Этәргеч булсын иде.
Чишмә яннарын җиһазлап,
Ял итү булсын иде.

Игелекле бәндәкәйләр,
Ярдәм итәр чишмәгә.
Мал кермәскә чорнап алсаң,
Изге булыр чишмә дә.

Безгә килеп эшләмәсләр,
Үзебез тырышмасак.
Ял итәргә урын булыр,
Тырышаек бергәләп.

Без олгайдык, чишмәләрне
Яшь чактан ук карадык.
Шушы чишмә суын эчтек,
Башка җиргә бармадык.

Картлык килер бер заманны,
Борылып артка карарсың,
Булганнарын да бетерсәң,
Соң син кемгә ярарсың?

Рәзит, Мәҗит, безнең әтәй,
Чишмәләрне карадык.
Элеккедән матур булсын,
Утыртыйк чәчкәләрне.

## ГАРМУН АЛДЫМ КУЛЫМА

Гармун алдым кулыма,
Чыктым барыр юлыма.
Сәхрә кошлары кушыла,
Гармунымның моңына.

Тургайлы сәхрә юллары,
Офыкларга тоташа.
Минем дә гомер юлларым,
Уздылар офык аша.

Сайрый, сайрый тургайлар,
Күтәрелә офыкка.
Яшьлек тә бит сайрар коштай,
Тыеп булмый тотып та.

Гомер көзем ишек кага,
Кайда качып калырга.
Булганнарына шөкер итеп,
Тальянымны тартырга.

Гармунымның сихри көче,
Өнди мине яшәргә.
Эчемдәге изгелекләр,
Гармун моңына кушылып.
Калсын иде яшьләргә.

Берәр кайтып булыр микән,
Нык теләсәм, тырышсам.
Барлык изге теләкләрем,
Ашыр микән тормышка.

Балаларым, сезгә калсын,
Тормышымның алмасы.
Яшәң яшьнәп, рәхәтләнеп,
Үкенечкә калмасын!

## ЯЗМЫШ

Язмышлардан узмыш юк дип,
Дөрестер әйткән сүзләр.
Яши-яши дөреслеген,
Белеп күрәдер күзләр.

Яшь вакытта, көч барында,
Язмыш синең кулыңда.
Ә картайгач тараядыр
Синең барыр юлың да.

Заманында ничек кирәк,
Шулай яшимен - диясең.
Ә картайгач, ничарадан бичара - дип,
Язмышка баш иясең.

Заман белән язмыш бергә
Килеп керә тормышка.
Белә торып ялгышканнар,
Тап булалар орышка.

Язмыш нигә нык аяусыз,
Чирен куя картлыкка.
Яшьлектәге хәтирәләр,
Калкып чыга картлыкка.

Язмышмы ул? Ялгышмы ул?
Гәҗәеп хәзер, дөньядан да туялар.
Көн-таң атса көйсезләрне,
Ахирәткә куалар.

Яше-карты берөзлексез,
Күз яшьләрен түктеләр.
Дөньялыкта калганнары
Аяк өсте киптеләр.

Бу тормышны аңламассың,
Барысы да бер кебек.
Ярлыларга яшәү начар,
Суы да бетте кибеп.

Язмышмы ул, Гитлер бетте,
Торып калды затлары.
Булмас димә тагын шулай
Корал тотып баш калкытыр,
Шул ук фашист калдыклары.

Язмышыма үпкәләмим,
Әле мин җитмеш яшьтә.
Яшисе килә, типтереп,
Җитмеш яшькә җиткәч тә.

Заманаы күрдек инде,
Тарихта иң яманы.
Гасырлар да җавап тапмас,
Яманның да яманы.

Хәзер замана икенче,
Кем нинди бәһа бирә.
Галәмендә очып йөреп,
Айгада менеп биер.

Яшь вакытта да күрдек без,
Немецның явызлыгын.
Хәзер дә бар явызлар,
Салганнар авызлыгын.

Дөньялыкны бетермәскә,
Кирәк белеп яшәргә.
Без күргәнне күрмәсеннәр,
Шуны телик яшьләргә.

## ҖЫРЛЫЙК ӘЛЕ

Мин уйныймын гармунымны,
Син дә җырлап ал әйдә,
Урамнан узган кешеләр
Кунак җыйган дисеннәр.

Шахта көен уйныйм әле,
Күтәрелсен күңелләр.
Без үзебез башламасак,
Җыр башлардай түгелләр.

Узган елны искә алып,
Каршы алыйк яңасын.
Бокалларга шампань тутырып,
Күтәрик узган елга.

Эх, дусларым, сезгә әйтәм,
Берүк яшәп калыгыз.

Алар да бит яшәде дип,
Безне искә алыгыз.

Иртән торып тышка чыксам,
Күзем төшә күршегә.
Күпме теләсәм дә булмас,
Кире кайтып күршергә.

Үзем уйнап, җыр башласам,
Бозмам микән табынны.
Табынны бозудан курыкам,
Сез дусларым ягымлы.

Үзем уйнап, җыр башлыймын,
Сез күтәреп алыгыз.
Мәҗелесләр ямьле булса,
Сагынып искә алыгыз.

Туганнарча хөрмәт итәм,
Килеп кердегез безгә.
Сезнең белән табын ямьле,
Ни хөрмәт итим сезгә.

Эх, дусларым, сез җырлагыз,
Мин уйнаган көйләргә.
Күңелдә калсын бу мәҗлес,
Һәрчак сагнып сөйләргә.

Үзем уйнап, җыр башласам,
Сез күтәреп алыгыз.
Кат-кат тагы туып булмый,
Берүк яшәп калыгыз.

## ГАҖӘПЛӘНӘМ ҮЗЕМӘ

Йөгерә-йөгерә җиләк җыйдым,
Биек тау итәгендә.
Уйлап-уйлап хайран калам,
Ник болай икәнемә.

Ярый күңел күтәрелә,
Гармун алып уйнасам.
Аяк аксак, колак тонган,
Бу картлыкның җимешедер,
Төптәнерәк уйласаң.

Ярай күршекәйләр керә,
Картайган дип тормыйлар.
Клубка да чакыралар,
Ярамый дип тормыйлар.

“Ахирәт”тә бик еш булам,
Бар да керәләр төшкә.
Яшәү елы кыскарадыр,
Җитәлмәм сиксән яшькә.

Аллаһыма рәхмәтлемен,
Әле дә болай яшәдем.
Картлар белән мин нишлим дип,
Җыядыр ул яшьләрен.

Бурычлы булып калмаммы,
Әҗәткә алганнарга?
Куям риза-бәхиллекне,
Үземнән калганнарга.

Бик күп сүзләр әйтми калам,
Үземнән көлгәннәргә.
Ходай бар ул, кире бирә,
Үзләре белгәннәргә.

Үзем белгәннәрне теләп,
Укыйм илә намазны.
Хәзер кеше шашып узды – вата-кыра,
Белми гүрнең газабын.

## УЙЛА, ХАЛКЫМ

Россия ул рогоносец,
Мөгез тотып торучы.
Ә миллионер-миллиардерлар
Россияне савучы.

Социализмны хурладылар,
Ярлылар яклы булгач.
Капиталист шартлар әле,
Берәр убыры тулгач.

Кризис диеп, сәбәп табып,
Бетерделәр колхозны.
Завод җимереп, тимер сата,
Күрмиләр дә комсызны.

Җирен сата, газын сата,
Нефтесенә чут та юк,
Калган җирдә чүп-чар үсә
Халык өчен чурт та юк.

Ходай тәгалә дә хәзер,
Байлар ягына күчте,
Җәй буена бер яңгыр юк,
Коеда сулар кипте.

Әй, кешеләр, уйлаң әле,
Уйлаң әле, кайда сез?
Үзгәртеп кору – бай өчен,
Халык өчен файдасыз.

Яшьләр курка өйләнергә,
Торыр җире булмагач.
Семья корып, яшәр өчен
Эшләр эше булмагач.

# ШУЛАЙ ДА БУЛА

Бу дөньяда утта, суда,
Законга туры була.
Закон бозган һәрбер нәрсә,
Дөньяның хуры була.

Дөньялыкның үз законы,
Үләнкәйләр дә парлы.
Парсызларның рәхәт кенә,
Дөнья көткәне бармы?

Күп чагында төзәлмәстәй,
Яралар да төзәлә.
Проблема булмый тормый,
Сабыр итеп түз аңа.

Түзәлмим дип уйламыйча,
Араны да өзерсең.
Кире ялгау уең булса,
Бик күп сумга бөлерсең.

Җиде үлчәп, бер кат кис - дип,
Әйтүләре бик дөрес.
Каршы алучы булмаса,
Кайтырсың дөнья күреп.

Каты-коты мөгаләмә,
Өзә яшәү җепләрен.
Үзең генә кеше булсаң,
Эзләмә гаепләрен.

Атта да бар, тәртәдә дә,
Арба тора кузгалмый.
Холыкыңны төзәтмәсәң,
Утырырсың күз алмый.

Барыр юллар еракләша,
Туп-туры булганда да.

Тормыш көтү бик катлаулы,
Нык туры булганда да.

Кар бураннары чепуха,
Кулында булса көрәк.
Үзгәреп тора тормышлар,
Яраклашырга кирәк.

Намуссызлар бу дөньяда,
Вождан сатып көн күрә.
Ата-анасын рәнҗетсә,
Гомергә иза чигә.

Язасына сагалыйдыр,
Ходайның да әмере.
Үз сүзлелек, тискәрелек тә яшәсә,
Юк аның арткан җире.

## УЙЛАНДЫРА ИКӘН УЛ

Гармун алсам кулларыма,
Яшьлегемә кире кайткандай булам.
Бездән алда туганнар да,
Картлыкка дучар булган.

Яшь чакларда кичергәннәр,
Төшләреңә кермәсен.
Шатлыклы көннән башкасы
Кире кайта күрмәсен.

Гомеркәйләр үтте инде,
Искә генә алабыз.
Көннән-көн үзгәртеп корудан,
Шыр яланга калабыз.

Яшьләр китсә, мәктәп бетсә,
Авылның төсе китә.
Гомер көзе якынлашкан
Картлар да күчеп китә.

Киләчәктә туристларга
Йөрерләрме аңлатып.
Ижбулдыны белгән кеше
Тел шартлатыр, шак катыр.

Элеккене хәтерләргә,
Картлар калмады хәзер.
Тарих битен ачкан кебек,
Тезелеп торыр кабер.

Ярар иде искә алып
Балалар килгәләсә.
Заманакайлары үзгәреп,
Читләр генә килмәсә.

Уйланырсың, уйланырга
Әгәр урыны булса.
Дөнья бетмәс, җир яшәрер,
Дөньяга Гений туса.

## ТӨШЕРӘМЕН ИСЕМӘ

Тальянский гармунымны
Уйныйм белгән көйләргә.
Үтәр гомер, без булмабыз,
Калыр сагынып сөйләргә.

Яшь чакларны искә алып,
Уйныйм һәр чак шуларны.
Бергә үскән дус-ишләр юк,
Сагындыра шулары.

Түбән очтан Мәүли менә,
Батскийын уйнатып.
Ышнадан да Сабир чыга,
Тальян гармунын тартып.

Яз көнендә яшьләр менгәч,
Хан тавы да җанлана.

Гармун моңы, җыр-биюдән
Авыл өсте ямьләнә.

Язгы ташкын шавына кушылып
Түбән, киндер тукмыйлар.
Яшь чактагы моң-җырларны
Картайгач та хуплыйлар.

Клубларда тузан туза,
Зинияләр бииләр.
Өс киеме әйбәт түгел,
Уты да юк, биемибез димиләр.

Сәхнәләрдә лампа уты,
Спектакль куябыз.
Яшьләр дәртле, ашарга юк,
Кәлҗәмәдән туябыз.

Гөмеркәйләр үтте инде,
Без үткәрдек барын да...
Хәзерге яшьләр сакламый
Үз тазалыкларын да.

Сугыш дидек, без күрмәдек
Әти-әниләрне дә.
Тормыш үзе кулы белән изде,
Карт, гарибен, әби, бәбиләрен дә.

Үсә төшкәч, авылда бер
Флүр тарта хромка.
Бәйрәм саен, чират торып
Чакырабыз кунакка.

Үткәннәрнең кайтавазы,
Гармуным телләрендә.
Ходай сырхаулар бирмәсен,
Алдагы көннәремдә.

Иртән торсам – баш авырта,
Сиксән төя башымны.
Авыз тәмнәре югалды,
Ашап булмый ашымны.

Бөтен тәнкәйләрем сызлый,
Торалмыйм кайчагында.
Кадерен белеп яшәгез,
Гомернең яшь чагында.

Аяккайларым сызламый
Йөгереп йөрсәм иде.
Тотып алып, яшь чагымның
Кирәген бирсәм иде.

## ТОРМЫШ МӘКТӘБЕ

Кешеләрне кеше итә,
Бары тормыш мәктәбе.
Кайберләрне хайван итә,
Тоже тормыш мәктәбе.

Күргән, белгән нәрсәләрдән,
Алырга кирәк өлге.
Уку йортларында бары,
Анда каралган билге.

Кешелектә асыл сыйфат хасыйл була,
Дөнья гизгәндә генә.
Начарлыклар да яхшыра,
Аннан бизгәндә генә.

Урлап-талап байлык җыю,
Яшәү түгел – бер газап.
Тапканнарны саклай белүнең,
Яшәү шатлыгы озак.

## ФӘРИТ ДУС!!!

Кат-кат укыйм шигырь китабыңны,
Изгелегең шуннан күренә.
Күпме яхшылыгың юллар сала,
Әдәм баласының күңел түренә.

Укымаучы булса синең шигыреңне,
Күпме яхшылыктан мәхрүм ул.
Шигырь китапларың укып чыгучылар,
Йөзәр еллык фәһем алалар.

Бар да йөз яшәргә туган,
Җир йөзендә халык шигырым.
Кемлегеңне бик нык беләсең килсә,
Укып караң Фәрит шигырен.

Тугач, туган үз гомерен яшәр,
Ходай бирер үзе әмерен.
Үзең үлгәч якты эзең калса,
Белеп яшәү җирнең кадерен.

Дөнья күрә, рухи байлыкларны,
Үз эчендә йомылып калмаган.
Тәпи-тәпи йөреп укыганда,
Фәрит моны бик нык аңлаган.

Җиде түгел, унҗиде ел укып,
Әлифбаны гына ятладык.
Тырышмыйча гына диплом алып,
Яхшы тормыш көтеп ятмадың.

Тормыш шулай укыта да, уйната да,
Эшләргә дә үзе өйрәтә.
Баштан үткән бетмәс хәтирәләр,
Әле булса кайнар йөрәктә.

Рухи байлыгы көчлеләр
Упкыннан да сикереп чыгарлар.
Ил байлыгын йоткан убырларны,
Бер селтәүдә сугып егарлар.

Рәхмәт, Фәрит, синең горурлыгың,
Маяк бит ул безнең арада.

Очрашкач сөйләр сүзләр бетми,
Үткән юлкайлар да якты сукмак,
Гарьләнмибез артка карарга,
Хәтер сандыгымны актарам.

Синең турында язарга,
Каләм алдым кулыма.
Үткәннәрне хәтерләргә,
Чыгам барыр юлыма.

Үткән юллар – гомер баскычы ул,
Узганнарны барлап карасаң,
Язмыш юлын беркем үзгәртәлми,
Кайда кушса шунда барасың.

Без бәхетле, һич бер аерылмадык,
Очраштык кайчак көн аша.
Горурланам синең шигьри юллар,
Йолдызларга барып тоташа.

Фәрит түгел, Фәрсит идең бит син,
Укыганда мәктәп елларын.
Йөз яшәрләр кире яшьлегенә кайта,
Укыганда шигьри юлларың.

Дәрестә дә тик утырмый идең,
Кыерсыта идең кызларны.
Гафу ит син, берүк ачуланма,
Искә алу бит ул узганны.

## КИРӘГЕ ЧЫКСА

Үтенеп ярдәм сорадым,
Аңларсың микән берәр.
Чын әдәм баласы булсаң,
Аңларсың әле диләр.

Чын күңелдән ярдәм итсәң,
Үзеңә дә шул булыр.
Үрсәләнгән нужаң булса,
Хазинаң тулы булыр.

Тормыш бит ул җиде катлы,
Берсе барда синеңчә.
Барыр юлларың тайпылса,
Булыр бар да үзенчә.

Тормыш кайчак көйсез кияү,
Көйгә килмәсә кыен.
Кайда барсаң да уңмассың,
Өстәлдә бетсә сыең.

Күз өстендә каш чагында,
Карый бар да үрелеп.
Каш карайтып күз чыгарсаң,
Бер кем йөремәс күренеп.

Байлыкларың мулдан булса,
Барда дус та, барда яр.
Авыз ачкач үпкәң күренсә,
Бар да яныңнан таяр.

## УРАК ЧҮКЕЧ БӘЕТЕ

*07.12.2010 ел*

Мин әйтәем сез тыңлагыз,
Урак-чүкеч бәете.
Урак-чүкеч юкка чыкты,
Кемнән эзлик гаепне.

Урак-чүкеч дус чагында,
Халык йөреде аш-суга.
Хәзер икмәге дә үсми,
Чүп-чар үсә басуда.

Үз кесәң дә байлык якын,
Кирәк чакта алырга.
Читләр биргән байлык заты,
Хәер генә калдыра.

Урак-чүкеч горурланып,
Торды кантур түрендә.
Хәзер халык бер-берсенә,
Шайтан булып күренә.

Ил байлыгын җитәкләде,
Урак-чүкеч байрагы.
Тыныч яткан күл комланды,
Үсеп чыкты байлары.

Урак-чүкеч партиясы,
Илле бишкә ярылды.
Тарих үзе нәрсә дияр,
Бу чор күпкә барырмы?

Думадагы депутатлар,
Белмим күпкә чыдармы?
Ил байлыгы совсем беткәч,
Чыш-пыш кына чыгармы?

Көн-таң атса, үлеш-талаш,
Телевизор хәбәре.
Үз ботагын үзе кисә,
Булмас моның кадере.

Эшчеләргә эш булмагач,
Кайда, ничек яшәргә?
Яшәү шарты булмаганга
Азды хәзер яшьләр дә.

Крәстиян баемады,
Күп булды ашар тамак.
Капиталистлар баеды,
Крәстиянне талап.

Крәстиян нык тырышты
Кәкерәеп беткәнче.
Капиталист шашты, шашар
Үз башына җиткәнче.

Уракта шул крәстиян,
Чүкеч күпме төйгәндер.
Илне ачлык кашыгында,
Белмим күпме көйгәндер.

Илдә хаос, хуҗалар юк,
Җавап бирми бер кем дә.
Читләр килеп басып алса,
Илдә калмас берсе дә.

СССР исән чагында,
Җир шарын әйләнделәр.
Үзгәртеп кору азагы,
Чүп-чарга әйләндерде.

Тарих укыган кешеләр,
Күп нәрсәне беләләр.
Кризис дип баючылар,
Бәндәләрдән көләләр.

Язар сүзләр күпләр алар,
Язылмый эчтә кала.
Ахри заман якынлаша,
Дөньясы шуңа бара.

## ХЫЯЛЫЙ

Хыялый булып тумыйлар,
Хыялландыра дөнья.
Кылган эшең уң булмаса,
Күп уйландыра шунда.

Башларыңа уйлар төшсә,
Уйлыйсың да уйлыйсың.
Көн уйлыйсың, төн уйлыйсың,
Уйлавыңны куймыйсың.

Намуссызлар кыерсытса да,
Нервыларга кагыла.
Күп уйлаудан сары сагыш,
Йөрәкләргә сарыла.

Авыр сүзнең ялары,
Тән ярасыннан авыр.
Кары эрер, бозы калыр,
Башыңда эзе калыр.

Кайгы ходай күрсәтмәсен,
Хыялның зур газабы.
Юләрләнүгә китерер
Бу газапның азагы.

Мәхәббәт ул - һәр кемгә дә,
Хыяллану баскычы.
Бу карт дими, бу яшь дими,
Үз кулыңда ачкычы .

## ЭХ, ЗАМАНА!

*06.03.2011ел.*

Тарихтан гына укыдык,
Полицай дигән сүзне.
Олыгайгач килеп басты,
Алга полицай үзе.

Жандарм да килеп җитәр,
Гомер булып яшәсәк.
Сугышы гына булмасын –
Бар да бушка китәчәк.

Социализм тамырында
Калгандыр черек җире.
Шул череген тазартсалар,
Тагын кайтырмы үзе.

Кәбестәнең катлы-катлы
Булуын без беләбез.
Үзгәртүнең катлануын
Хәзер килеп күрәбез.

Бай катлам белән ярлылар
Кайчан соң дус яшәгән?
Бай катламы бер заманны,
Туктаган бит яшәүдән.

Ярлы мескен яшәгәндә,
Ниләр генә күрмәгән.
Байлар кебек, бер кемне дә,
Тере килеш күммәгән.

Хәерчеләр көннәр буе,
Хәер сорап йөрегән.
Бай катламы илне талап,
Алтын таулары өйгән.

Мөмкин кадәр игътибарлы
Булып яшәсәк иде.
Именлекнең кадерен белеп,
Сакларга кирәк илне.

Ходай тагәлә әйткән бит –
Сакланганны саклыйм – дип.
Сакланмагач, капиталист
Алга килеп басты бит.

Бу карашка тормыш хәзер,
Күп нәрсәләр кичерде.
Гөрләп торган заводларны,
Колхозларны бетерде.

Илдә хәзер эшсезләрдән
Рекорд куйдык дөньяда.
Яшәүнең дә кызыгы юк,
Барда ялган булганга.

Читләр килеп төзиләр бит,
Компания дигәнне.
Туя ашарга да җитми,
Хезмәт хакы дигәне.

Урыскайлар исән булсын,
Бар да порядок булыр.
Баеганнар читкә качса,
Читкәйләр килеп тулыр.

## ӘЙТИМ ӘЛЕ, ЭЧЕМДӘГЕ ТЫШЫМДА

Бездән алдагы картлар да,
Бик күп михнәт күргәндер.
Кирәк чыдамлык яшәргә,
Тырышкандыр, түзгәндер.

Берәр гасыр яшәгәннәр,
Нәрсә генә күрмәгән.
Ушы булган аның үз башында,
Шуңа күрә үлмәгән.

Яшәүнең дә җае бар бит,
Юк-барга әрәм итмә.
Ходай биргән нервыңны,
Хәмер дә күрсәң, яшәү көчен,
Тиз күрерсең гүреңне.

Яшәү җиңел, озын гомер,
Иңеңә төшкән авырлыкны
Җиңәргә белсәң генә,
Өстәлендәге хөрмәтнең
Кадерен белсәң генә.

Семья карап яшәүнең дә,
Бар четерекле ягы.
Муллык белән җитмәүчелектә яшәргә
Туры килә күп чагы.

Тормыш булгач күп чагында
Ормышка да әйләнә.
Җитмәүчелек хөкем сөрсә,
Хатын да еш бәйләнә.

Хәзер тормышның газабы –
Хатын-кызлар тартуы.
Эчсә-тартса, «гулять» итсә,
Килә ирләр ярсуы.

Болай яшәү – тормыш түгел,
Көймә комга терәлү.
Бу семьяның азагы шул,
Упкынга барып төшү.

Борын-борыннан булгандыр,
Тормыш яшәү серләре.
Күп илләргә сугыш кирәк,
Җитми яшәр җирләре.

Хәзер күпкә җиңелерәк,
Яшә дә, яшә генә.
Комарланып байлык җыя,
Этенә дә сарай сала,
Ярлы мескен эшсез кала.
Көн бирми яшьләргә дә.

Минем белгән шәҗәрәдә,
Йөзгә җитә буыным.
Тагын өстәп шуны язам,
Кешегә төшкән бурычны,
Бетерү минем уем.

Шәҗәрә:
Газга түләү, утка түләү,
Түләми ашамыйсың,
Чутка тыксаң йөздән арта,
Ашабырак чыксаң юлга,
Акчасыз ташламыйсың.

Шул кадәрле акчаларны,
Каян тапсын хәерче?
Күрә торып җимерәләр
һәм талыйлар,
Җавап бирәме берсе?

## ТАРИХТА БЕР МИЗГЕЛ

*30.04.2011 ел.*

Илнең астын өскә китерделәр
Ельцин белән Горбачев.
Тагын кире кайтмас микән
Салават белән Пугачев?

Илдә хуҗалар булмагач,
Беткән колхоз корылмас.
Илне хәерчелек басты,
Капитализмны коргач.

Баш киемен борып кына,
Артка борын үсми ул.
Тарих бит ул нык хәтерле,
Исәпләми күчми ул.

Тарих өчен ике мең ел,
Бер тамчы су диңгездә.
Безнең гасыр кире кайтмас,
Үтәр еллар, йөз, мең дә.

Котыпта да боз кузгала,
Җылыну эрү шарты.
Җир шарында халык шулай
Капитализмга каршы.

# ИЛ ЯЗМЫШЫ

Россиянең гербында
Ике башлы карчыга.
Икесенә бер акыл юк
Талашып яны чыга.

Урак-чүкеч һәм башкалар
Урап тора җир шарын.
Урак-чүкеч аерылып,
Юкка чыгарды барын.

Кызыл байрак, шушы герб
Булган икән ил яме.
Башсыз Горбач аркасында
Тормышның бетте гаме.

Шулай дими – нәрсә дисең,
Җиңел акыллы булгач.
Урамдагы хатын-кыздан
Акыллар сорап торгач.

Үзгәртеп корабыз диеп,
Ил язмышын кырдылар.
Чәчмәсәк тә – урабыз дип,
Колхозны туздырдылар.

Коралларны металлалом дип
Чит илләргә бирделәр.
Без бит хәзер капиталист,
Курыкмыйбыз диделәр.

Капиталист ике йөз ел
Байлык җыеп үткәргән.
Без мескеннәр илле еллап
Сугыш күрми көн күргән.

## СЫКРЫЙ КАРТЛАР ЙӨРӘГЕ

Җирән атым йөк тарталмый,
Менеп булмый үрләргә.
Күрәсеңне күрмиенчә,
Кереп булмый гүрләргә.

Бер кем төшенә кермәгәндер,
СССР таралуы.
Һич кенә дә тынгы бирми,
Авылның таркалуы.

Кем каргышы төште микән,
Бу кадәр иттерергә?
Кирәкми икән бик күп көч,
Бу хәлгә җиткерергә.

Йөрәк ярсый, түзеп булмый,
Бу кадәр мәсхәрәгә.
Гөрләп торган авылымны
Куялар сәхерәгә.

РайонДагы җитәкчеләр
Күреп-белеп торалар.
Ижбулдыны бетерергә,
Бик зур план коралар.

Ижбулдының гомер көзе
Шулай килеп җитәрме?
Газы да юк, суы да юк,
Соснау кебек бетәрме?

Авыл халкы да картайды,
Яшьләре бар да читтә.
Бәлки әле яшәрбез дип,
Нигез салдык мәчеткә.

Ходай кушса, бу хыяллар
Бәлки ашар тормышка.
Белеп булмый киләчәктә,
Ни буласын тормышта.

Вакытлыча мәчет булыр диеп,
Контораны биреп торалар.
Манарасыз була мени мәчет,
Анысын да эшләп коралар.

Киң күңелле Ижбулдыны
Азербайжаннар басты.
Алар шундый мәнсез халык,
Авылның коты качты.

Торган җирен дә карамый,
Баскан әрем, кечерткән.
Машина белән йөриләр,
Бер туктаусыз кич-иртән.

Район көче белән берчак
Юллар булды асфальтлы.
Паровоз кебек КАМАЗ белән.
Издерделәр асфальтны.

Үтәрлек тә түгел хәзер,
Урамкайны ашага,
Ничек чыдап яшәргәдер,
Бу кадәр тамашага?

Мин әйтәем – сез тыңлагыз,
Узем язган бәетне.
Үз өстенә кемнәр алыр,
Бу кадәрле гаепне?

Авылым турында бәет
Язып куярга булдым.
Ялган булса язганнарым
Корысын ике кулым.

Мал карасаң – саламы юк,
Басуы белән яндыра.
Халыкның бөтен байлыгын
Коры җиргә калдыра.

Кар суын файдаланып,
Малларга эчерәбез.
Ленинград кашавынын
Хисләрен кичерәбез.

Эчер суларга интегеп
Яшәү була микәнни?
Яшәү шартын яхшыртырга
Кайдан табыйк бүтәнне?

Чишмә суына төшәргә,
Иртән план корабыз.
Шобага кемгә эләгә дип,
Тын да алмый торабыз.

Ходай каргап шушы хәлгә,
Төшерде микән әллә?
СССРда бер кайгысыз,
Яшәп калганбыз әлдә.

Колхозны да бетерделәр,
Өлге итеп районда.
Булган мөлкәтен кыралар,
Әйтми-нитми районга.

Сугыш кырын хәтерләтә,
Ферма янына баргач.
Кемгә ничек яшәргәдер,
Шып-шыр яланга калгач.

Башымдагы хыялымны,
Ак кәгазьгә күчерәм.
Гомеремдә кичергәнне,
Исләремә төшерәм.

Авылым турында язарга,
Күптән уйлап йөримен.
Куркыныч төш кергән сыман,
Сыкырана йөрәгем.

Ижбулды турында элек
Мактап сөйлиләр иде.
Урамнарда гармун уйнап
Җырлап йөриләр иде.

Гөрләп торды клубыбыз,
Яшьләр пьеса куйдылар.
Үзешчәннәр смотрында
Беренчеләр булдылар.

Колхозы да вакытында
Беренчеләрдән булды.
Дәүләт планнары һәр чак
Башкадан алда тулды.

Зыяз белән Ниязларның,
Убыры тулыр микән.
Ходай күреп, бу эшләрне
Берәр чик куяр микән.

Урамдагы колонкадан
Гөрләп акты сулары.
Оҗмахтагы сыйлар кебек
Искә төшә шулары.

Җәен яңгырлар яумаса,
Суны «качать» итмиләр.
Атнагул суы – безнең су,
Шуны аңлап җитмиләр.

Гөрләп торган МТМ дә,
Калды хәзер тырпаеп.
Скелеты гына калды,
Үлгәнме әллә картаеп.

Ферма корпусларын көн-тән,
Эй кыралар шак та шок.
Узган кешеләр хайран калып,
Тел шартлата шак катып.

Ижбулды да шулай булгач,
Бүтәннәргә үпкә юк.
Ижбулды ул нәрсә генә,
СССР бит күптән юк.

Явыз Гитлер үз халкының
Байлыгын җимермәде.
Безнең явыз һич аямый,
Бар мөлкәтен җимерде.

Борын-борыннан бабайлар
Шушы җирдә яшәгән.
Иген иккән, мал караган,
Тирен түгеп эшләгән.

Әти-әниләр шул җирне,
Бер колач җирен бирми.
Көне-төне ач-ялангач эшләп,
Бөтен көчен бирә колхозга.

Әтлегәчтә бердәм халык
Бер колач җирен бирми.
Петерәм хәзер, шошкеләм - ди,
Бер кайда да йөреми.

Безнең мескен, юаш халык,
Үз паен сорый белми.
Сораганнарга бирмәгәч,
Судларга да йөреми.

Алтмыш еллык җинү көне,
Ветераннар сугышы.
Бер заман төшәр әле,
Аларнын да каргышы.

Әй түрәләр, түрәләр,
Безне барда күрәләр.
Каруннар да күп яшәми,
Барыбер берчак үләләр.

Әйтер сүзем шул, туганнар,
Кайтарып алыйк әле.
Безгә беркем китереп бирмәс,
Шуларны аңлыйк әле.

Ижбулдының тамыры нык,
Бетәргә тиеш түгел.
Читтә булган бәндәләр дә
Уйларга тиеш бүген.

Ата-баба нигезләре бетсә,
Кемгә кайтып керерсең?
Хайран калып, исәнкерәп
Йөрерсен дә йөрерсең.

Балаларым аң булыгыз,
Берүк калмыйк бу көнгә.
Керер җирең, эчәр суың да булмаса,
Яшәп булмый бер көн дә.

Башымдагы уй-хыялым
Язып бетәрлек түгел.
Авыл язмышы турында
Уйларга кирәк бүген.

Көн җылынса, күтәрелә
Агыйдел томаннары.
Үлгәч тә бәлки, онтылмас
Күнелдә торганнары.

## ТҮРӘЛӘРГӘ

Бу дөньяда күпләр алар,
Әйткәнне аңламаган.
Үзен-үзе зурга куеп,
Башканы санламаган.

Аермый яхшыны яманнан,
Күрмидер күнел күзе.
Мин-минлектән уза алмый,
Сөйләгән һәрбер сүзне.

Фани дөньяның байлыгы
Гел аңа гына булсын.
Җир шарының бөтен халкы
Гел аңа карап торсын.

Җирдә түгел, айга менеп
Карый кайбер түрәләр.
Кискен хәрәкәт ясаганны
Күктән җиргә сөрәләр.

Дөньялыкта бу гамьсезләр
Белми халык кадерен.
Шайтан таяклары бассын
Үлгәч анын каберен.

Ахирәттә закон башка
Анда бар да тигезләр.
Ришвәт биреп котылу юк,
Тамуг үзе тигезләр.

## СИНЕ УЙЛАСАМ

*28.07.2010 ел*

Мин сагынсам гармун уйныйм,
Җырларсыңмы гармун уйнасам?
Искә төшә үткән хәтирәләр,
Үзем елыйм,үзем уйнатам.

Эй, яшлегем, кайт син кире
Төшләремдә  булса да!
Утырасы иде бер гөрләшеп,
Бик күп түгел, минут булса да.

Киләчәккә җырлар язып,
Куяр идем искә алырга.
Мәхәббәттә бары сихри көч,
Әйтә алар истә калдырып.

Гармунымны алып үзем җырлыйм,
Яшь чакларым искә төшкәндә.
Кайтавазым синдә бар өметем,
Яшәү дәртем бетеп киткәндә.

## АҢЛАШЫЛМЫЙ

Бәндә баласы дөньяга,
Ник туганын аңламый.
Тормыш корып, кемгә эшли,
Анысын да аңламый.

Газап чигеп,тормыш кора,
Бернәрсә дә аңламый.
Яшәешне аңлаганнар,
Барысын да алдалый.

Көнгә чыксаң гәҗәп түгел,
Ил байлыгын талыйлар,
Җир байлыгы – ил байлыгы,
Үз җиренә дә хуҗа юк,
Шуны хәзер даулыйлар.

Бик күпләр хәзер байыйлар,
Хәерче хисабына.
Хәерче беткәч нишләрләр,
Кермидер исләренә.

Вата, кыра, кала кора,
Хаерчене талыйлар.
Ул баесын димиләр,
Өйгән алтын тавы кала,
Ә анысын белмиләр.

Яшәешне галимнәр дә,
Бик дөресен аңламый.
Гомер буе бергә яши,
Берсен-берсе аңламый.

Ярый әле үлем тигез,
Бар да тигез оҗмахта.
Ярлы үлеп,байлар калса,
Юл да бирмәс оҗмахка.

## УЙЛАНЫРГА УРЫН БАР

*30.04.2011 ел.*

Май аенда яфрак яра
Бакчадагы алмагач.
Нигә интегеп яшәргә
Мәхәббәтең булмагач.

Яшәп-яшәп күпләр белми,
Кайчан үлеп китәрен.
Алданырак белмәгәнмен,
Нервыларым бетәрен.

Нервы бит ул кешелекнең,
Иң югары бер көче.
Нервысы беткәч яшәми,
Фани дөньяда кеше.

Запас саклап яшәгәннәр,
Бер гасырын да яши.
Уйламыйчарак ярсысаң,
Китеп барасың яшьли.

Бухгалтерлар еш ялгыша,
Хаталарын аңлыйлар.
Психланып хаталанган,
Кире кайта алмыйлар.

Ярату сүзе чыгарсаң,
Буласың олы дошман.
Яратырлык җир булмагач,
Лучше язасың уштан.

Соңгы көчемә чаклы яраттым,
Белмичә гомер көзен.
Кешеләргә тиң түгелне,
Шуны белмәдем үзем.

## ГӘЕПЛӘМӘ

Хатыныңа  бүләккә
Чәчкә бирми калмагыз.
Җитмешнең дә ар ягында
Кызарыр бит алмагыз.

Гөмеремдә бүләк өчен
Чәчкә өзеп алмадым.
Күрдем, чәчкәсез кәүсәнең
Жәл, тырпаеп калганын.

Чәчкәләр кыска гомерле,
Суга салсан да шиңә.
Озак-озак шиңми торган
Бүләкләр эзлим сиңа.

Ул бүләгем зур мәхәббәт,
Сөю һәм шәфкәт булыр.
Бу сүзләрнең мәгънәсе,
Мәңгелек дуслык булыр.

Бер нинди дә бәһа юктыр,
Миңа булган хөрмәткә.

Балалар белән туганнар
Һәрчак булды хөрмәттә.

Кулдан килсә бирер идем
Таң нуры алсулыгын.
Әле булса сокланырлык,
Үзеңнең алсулыгың.

Бала-чагалар хәсрәтен
Күрерләргә язмасын.
Саф мәхәббәт, тигез гомер
Үкенечкә калмасын.

## КАРТЛЫК ЯШЕН КҮРМӘЕНЧӘ

Картлык яшен күрмәенчә
Яшьләр үлә еш кына.
Була тормыш юшкыны,
Алдыңда ни кушканы.

Ир-егетләр әйләнәләр
Чирле-чорлы картларга.
Үткәннәр белән мактанып
Тик утыра картлар да.

Көнгә чыксаң таяк сөйрәп,
Аксап йөри карт-коры.
Яшьлегенең яшәү ямен
Ашады сугыш чоры.

Хәзер халык шашып узды,
Шартлаталар дөньяны.
Күпләр алар, шашынуның
Үз башына булганы.

Бер гаепсез газиз җаннар
Меңәрләп кенә үлә.
Ахри заман явызларга
Көткәннән алда килә.

## ТӨТЕН ИСЕ

*07.10.2010 ел.*

Хәзер килә төтен исе,
Син үзең сизмисеңдер.
Китәсең дә югаласың,
Кайларда йөрисеңдер.

Әйткән сүзең туры килсә
Ходайның аминына,
Бездә бәлки кушылырбыз
Тормышның агымына.

Ялгызлыкның ачы суы
Үтеп керә үтләргә.
Рәхәт тормыш тынгы бирми
Сала янгын-утларга.

Ходай ярдәм бирер микән,
Аерылып калганнарга.
Бирәр әҗер булыр әле,
Утларга салганнарга.

Күз яшьләре кибер әле
Чишмә сулары кебек.
Үтсен иде бу афәтләр
Чирдән терелгән кебек.

Туар таңнар булсын шатлык белән,
Хәсрәт таңы булып тумасын.
Гомеркәйләр үтте, тагын үтәр,
Тормышкайлар гына тузмасын.

Илгә төшсә – бөтен ил күтәрә,
Өлешеңә төшкән көмешең,
Ялгыз башка хәсрәт төшсә,
Ул хәсрәт эшләр үз эшен.

Авырлыккайның матурлыгын
Менеп кара үрләргә.
Явызларның явызлыгын
Төзәтә алмас гүрләр дә.

## ӘЙ, СЕЗ!

*10.01.2012 ел.*

Әй сез, гайбәт ияләре!
Уйнамаң язмыш белән.
Һәр вакыт гомер өзелә,
Уйлаудан ялгыш кына.

Нахак сүзгә рәнҗетелеп
Күпме гомер өзелә.
Күпме гомер өзгән булсаң,
Рәнҗешләре үзеңә.

## ЧУКЫМА

Кызып китеп, очып килеп,
Бердә юкка чукыма.
Чукыгычлар чукый-чукый,
Берзаманны чукына.

Килеп-килеп искә төшә,
Рәнҗетсәләр нахакка.
Тырышсаң да әз эшләнә,
Яхшылыклар күп чакта.

Яшәй-яшәй үткәннәр дә,
Искә төшәр тормышта.
Яхшымы ул, начармы ул,
Шуны ура торырсың.

Ходай үзе риза булса,
Өеп бирер байлыгын.
Эчкән суыңа төкерсәң,
Юкка чыгар байлыгың.

Бер дә юкка тормышны да,
Кирәкми туздырырга.
Җилбәзәкләр дөнья тулган,
Тик вакыт уздырырга.

Бу дөньяның байлыклары,
Чамалап тотсаң гына.
Ашказаның озак яшәр,
Нык чәйнәп йотсаң гына.

Язмамдагы кайбер сүзләр
Булыр әле дөрес тә.
Күп чагында уңай чыкмай
Үз шәеңне белеп тә.

## ШУНЫ БЕЛ

*29.01.2012 ел.*

Әгәр булса мәхәббәтең,
Җөннән дә күпкә җиңел.
Исәнләшүче дә булмас
Көчең бетсә, шуны бел.

Җир шарын да яратмыйлар,
Мәхәббәте булмаса.
Эшкәртмиләр, ваз кичәләр
Җир дә уңыш бирмәсә.

Көн-төн эшли,төн йокламый
Мәхәббәт көчле булса.
Ир дә батыр,тормыш матур
Семьяда бала туса.

Иң мөһиме үз тормышын
Гәйбәт сүзләрдән саклау.
Төрле каршы киртәләрдән
Семья кыйммәтен яклау.

Байлык табу җиңел булса,
Аны саклавы мөһим.
Бер дә юктан, саксызлыктан
Юкка чыгарга мөмкин.

Авыр булса байлык табу,
Хакы да кыйммәтерәк.
Үз кадерен үзе белеп
Яшәүчеләр дә сирәк.

Гитлер әфәтеннән илне
Чыкты халык якларга.
Менә хәзер иң авыры,
Шул җиңүне сакларга.

Гитлер явыз канны эчте
Утыз миллион халыкның.
Әле булса бардыр шундыйлары,
Немец дигән халыкның.

Сак булырга, сакланырга
Шундый явыз затлардан.
Немецларга булышучы
Латыш дигән яклардан.

Җир йөзенең өсте түгел,
Астында да гел мәет.
Кайбер кара эчле әдәм затлары,
Сталинныда гаепләп,
Аңардан таба гаеп.

Җир шарының яралуын, тигезлим
Сугыштан калган җирләргә.
Җитмеш еллык хезмәт түгеп
Җыйган халык байлыгы
Эләкте шул каты җилләргә.

Күкереп торган колхоз амбарлары,
Җир йөзеннән юкка чыктылар.
Авылдагы мәктәп бетте,
Ул клубка артистлар да хәзер
Елга бер дә кереп чыкмыйлар.

Төшкә керә пьеса куйган чаклар,
Авыл саен кәмит куйганнар.
Берәр заман уйлап карарлармы?

Уйламаслар, төшкә генә керер,
Болар бездән совсем туйганнар.

Мәхәббәтең җөннән күпкә җиңел,
Җөнне генә тартып сузалар.
Көч куәтең әлҗе-мәлҗе булса,
Бер хәбәрсез-нисез узалар.

## АЛТЫН ТУЙ

Сез бәхетле, бик бәхетле,
Алтын туйга җиткәнсез.
Алтын бәһабәренә тиң,
Матур гомер иткәнсез.

Алтын орлык чәчкәнсездер,
Урожаегыз уңган.
Туганнар да, балалар да
Уңган урожай булган.

Сокланып карап торырлык
Алтын туй мәҗлесенә.
Киләчәктә шундый шатлык бир
Ходаем һәрберсенә.

## АЛТЫН ТУЙГА БАГЫШЛАП

*Рәфит белән Хәсинәгә*
*Сәлимә апагыздан.*

Юлларына гөлләр сибәр идем,
Әгәр килсә минем куллардан.
Тагын йөз ел өстәр идем,
Узып кына булмый ходайдан.

Ишек алдың яшел чирәм,
Әкрен генә кирәк атларга.
Җыелышып килгән балаларың,
Юбилеегыз белән котларга.

Анда бара, монда бара,
Гомер чаба, ашыга.
Коръәннәр белән укып каршы ал
Юбилеегыз хакына.

Бакчадагы алмаларың
Күзләр җитсә өлгерә.
Таза булып, исән-сау булыгыз,
Тагын шулай килер көннәргә.

Бакчадагы алмаларың
Күзен җыярсың микән?
Иң кызылын, иң зурысын,
Миңа куярсың микән.

Өйләреңә бараем,
Ак пәрдәләр элаем.
Безгә тагын артык нәрсә кирәк,
Сәламәтлек сезгә теләем.

Күп сәләмнәр белән
Сәлимә апагыз Гимаева

## ӘЙТЕР СҮЗЕМ

*01.05.2013 ел.*

Әй, оныгым, Линарым!!!
Уйларсыңмы мин барын.
Гармуннарым сиңа кала,
Төшкә керә уйнарың.

Ватма, сүтмә, озак сакла,
Өр-яңа кебек торсын!
Өйрән, уйнат матур итеп,
Авыл яңгырап торсын.

Гармун моңының серләрен,
Уйный-уйный сизәрсең.
Зурәтәңнән дә күберәк,
Дөньяларны гизәрсен

Дус-ишләрең дә күп булыр,
Аралашып йөрергә.
Син онытма, зурәтәңә
Кайчак хәер бирергә!

Әти-әниеңне тыңла,
Шәфкатле бул кешегә!
Уйна-җырла, күңел күтәр,
Дәртләр уят кешедә.

Изгелек ит, ярдәм күрсәт,
Ятимнәргә-картларга.
Бар эшең дә уңай булыр,
Үти алмас шартлар да.

## ХӘСИНӘНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

*10.08.2007 ел.*

Бүгенге көн безгә бәйрәм,
Ул - синең туган көнең.
Гомер бакый күкрәп яшә,
Бизәге булып җирнең!

Чәчәк бәйләмнәре бүләк итсәм,
Озак тормас алар – корыр ул.
Йөрәк җылылыгын бүләк итсәм,
Суынмастыр, җылы торыр ул.

Кояш кебек җылы сибәсең,
Йолдыз булып, нурлар чәчәсең.
Сулар һава кебек кирәксең,
Барыбызга канат, терәк син.

Кунелләрең сандыгында,
Бәхет-шатлыклар тулсын.
Гомеркәең аккан судай,
Туктаусыз озын булсын.

## НӘЗҺӘТКӘ 70 ЯШЬ

*Рәфит белән Хәсинәдән*

Бүгенге көн – олы бәйрәм,
Ул синең туган көнең.
Гомер бакый күкрәп яшә,
Безгә булып җирнең.

Тәбриклибез юбилееӊ белән,
70 яшь ул - чәчкә как кына.
Шулай тагын бик күп еллар,
Ныклап типсен синең йөрәгең.

Бәхеттә, шатлыкта,
Исәнлектә-саулыкта
Үтсен гомер юлларың.

Юбилейның иң гүзәле булып,
Мөхлисә дә килеп кушыла.
Киләчәктә туар таңнарыгыз,
Тигезләшсен тагын шушыңа.

Күпме булса җирдә изге теләк,
Телибез без сезгә барын да!
Ак чәчәкләр кебек бәхет яусын,
Туар көннең һәрбер таңында!

Йөрәкләрдә йөргән назлы сүзләр,
Күңелләрдә булган саф хисләр,
Озын гомер, саулык, ак бәхетләр –
Безнең сезгә әйтер теләкләр.

## ТУГАН КӨНЕҢ БЕЛӘН

*Рәмзиягә*
*06.03.2009 ел.*

Туган көнең белән кайнар котлап,
Җыйналдык без монда табынга.
Бу юбилей ул юл уртасы гына,
Шул кәдәрле яшә тагын да.

Бик күп изге теләк, олы хөрмәт,
Туры килде гомер уртасы.
Мәңге онытмассың бу көн синең,
Яшәү гомереңнең, тагын юл башы.

Барлык изге теләкләр дә
Ашсын иде берүк тормышка.
Балаларың, туганнарың белән
Рәхәт яшәң шушы тормышта.

Купме теләсәң дә аз ул сиңа,
Амин дисен берүк ходаем.
Чәчкәнеңнең игелеге булсын,
Ишелеп уңсын чәчкән бодаең.

## ХӘСИНӘГӘ ТУГАН КӨН БЕЛӘН

Туган көнең белән котларга,
Көтәм таңнар атканын.
Сәләмәт бул, шатлык белән,
Киләчәкнең һәрбер ал таңын.

Игелеген күр син балаларның,
Һәр теләген үтә аларның.
Чәчкәннәрең үсеп уңыш бирсен,
Барлык теләгәнең туры килсен,
Амин дигәненә алланың.

Чын күңелдән сине кайнар котлап,
Телимен сиңа изге теләк.
Кояш җылысыдай кайнар булсын,
Бергә типсен әле безнең йөрәкләр.

Онытылмаслык булсын еллар буе,
Туган көнең ямьле иртәдәй.
Өлге булып яшә балаларга,
Искә төшкәч исең китәрдәй.

Ходай биргән калган гомереңне,
Яшә яшьнәп исән-сау гына.
Туган көнең бик күп кабатлансын,
Алсу таңдай тагын-тагын да.

## УЙНА СИН ТАЛЬЯНЫҢНЫ

*06.02.2011 ел.*
*Захиткә*
*(көе «Уйна Тальян гармуныңны»)*

Уйнат Тальян гармуныңны,
Язлар җиткәч кичләрен.
Син уйнасаң бәреп чыга,
Эчтән яшьлек хисләрем.

Торып-торып искә алам,
Яшьлектәге үткәнне.
Күпме сер итеп саклаган,
Тальян безнең үскәнне.

Авылдашлар, мин җырлыймын,
Сез күтәреп алыгыз,
Җырым сезгә бик охшаса,
Сагынып искә алыгыз.

Эх, дусларым, олгайсам да,
Килә кайтып җырласым.
Сагынганда түзә алмый,
Килә ятып җыласым.

Уйнат әле гармуныңны,
Син уйнасаң – мин әйтәм.
Җиде төн урталарында,
Эх, дускаем – дип әйтәм.

Уйнат әле гармуныңны,
Үзең белгән көйләргә.
Син уйнаган, мин җырлаган,
Калсын сагнып сөйләргә.

## ТУЙ КӨНЕНӘ БАГЫШЛАП

Керсез йөрәкләрнең өмет белән,
Шатланышып бергә тибеше.
Туар көннәр матурлыгы өчен,
Туйлар булсын аның җимеше.

Туйлар үтсен ак калфагың киеп,
Шаулап торсын җырга,уенга.
Батыр уллар, матур кызлар,
Яшәү калсын килер буынга.

Зәңгәр күлдә йөзгән пар аккоштай,
Бәхет күлләрендә йөзегез.
Шатлык-куанычлар килеп торсын,
Боекмасын һәрчак күңелегез.

Ак чәчәкләр үсеп юлыгызда,
Ап-ак карда калсын эзегез.
Туегызда туган шатлык белән,
Елмайсыннар сезнең йөзегез.

Кушылып үскән пар каеннар кебек,
Бергә үтсен тормыш юлыгыз.
Авырлыклар булса, башлар ими,
Иңне-ингә куеп узыгыз.

Яшәгез кадер-хөрмәтнең
Кадерен белеп кенә.
Хәттә чикләвек төшен дә
Урталай бүлеп кенә.

Табыштыгыз, кавыштыгыз,
Зур тормыш алга дәшә.
Салкында да, ялкында да
Булыгыз гел янәшә!

## АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘ

Ак алъяпкыч, кара билбау
Нык килешә ирләргә.
Аденома, простатитка бирешәләр
Әзмәвердәй нык ирләр.

Простатит белән аденома
Әйтерсең бер туганнар.
Ир затларын газапларга,
Йөз яшәргә туганнар.

Аракы эчеп югалта,
Ир-егетләр башларын.
Артык эчсә семьясын да,
Башкасын да, оныта ул ашарын.

Хәзер замана буталды,
Эчә-тарта яшьләр дә.
Элек сугыш барын йотты,
Рәхәтләнеп яшәргә.

Агиделнең бозы калын,
Булырмы шартлатырга.
Ирләр эше бәлки калыр
Ясалма каплатуга.

Бу актуаль мәсьәләне
Бүген кирәк карарга.
Илдә халык саны кимеп бетсә,
Читләр кереп Россияне,
Саклап калса ярый да.

Бу чирләрне медицина
Чиргә чутлап бармады.
Ил сакларга бара торган,
Яшьләр дә күп калмады.

Булганнары армиядан
Качып-посып йөриләр.
Акча төртсә әти-әнисе,
Каралырга кермиләр.

Яшь кызлар да эчә, тарта,
Фәхешлектә йөриләр.
Ана булу читләп уза,
Бала "назы" күрмиләр.

Үз бәхетен үзе таптый,
Күрми тормыш рәхәтен.
Акча колына әйләнеп,
Шунда күрә бәхетен.

Ата-ана баласына
Баглый бөтен өметен.
Үз баласыннан күрмәсә,
Күрер кешенең хөрмәтен.

Бу мәсьәлә бүген килеп
Әйләнде көн үзәгенә.
Булган тормышың таркалса,
Үтмәсме үзәгеңә.

Бу дөньяның кадеркәен
Белми бай балалары.
Җир шарын да һәлак итәр
Капитал караклары.

Булган өстенә булдыра,
Җирен дә сата, маен да.
Үз халкына бирмәс өчен,
Читкә сата газын да.

Читтән ала азык-төлек,
Бармы аның файдасы.
Үз җирендә чүп үләне,
Эшсез халык, хәерчелек,
Миллиардердан файдасы.

## ЭХ, БАЛАЛАР!

*08.02.2011 ел.*

Бала бавыр ите диеп,
Белмичә әйтмәгәннәр.
Бу тормышта аларга да,
Әз нервы китмәгәндер.

Тормышлары көйле булса,
Чәчкә ата гөлләре.
Ата-аналар балаларга,
Багышлый гомерләрен.

Көйсез булса тормышлары,
Нык уйландыра икән.
Ходайдан ялынып теләүләр,
Ник бушка китә микән.

Уйламаска тырышсаңда,
Уй үзенекен итә.
Ашауны да нык кыскарта,
Яшәүне алып китә.

Нинди ялгышлык иткәндер
Бала тәрбияләүдә.
Җитмәүчелек кысылгандыр
Бала тәрбияләүгә.

Биштән торып печән чаптык,
Кеше-фәлән күргәнче.
Аннан ары эшкә чаптык,
Начальниклар килгәнче.

Иртән торгач әнкәләре,
Акча эзли авылдан.
Авылдагы берәр йорттан
Калды микән алынмай.

Әнкәләре килгән чакта
"Патша сарае" иде.
Юлга килеп төшмәсен дип,
Бик нык терәлгән иде.

Әлеге сүз йорт турында,
Таш түгел агач иде.
Ул елларга бик күп үтте,
Хәзер онтылган инде.

Балаларның афәте дә
Үтеп китсен төш кебек.
Ходайкаем ярдәмләшсен,
Балаларга көч биреп.

Бер көйләнсә тормышлары
Бар да онтылыр иде.
Алдагы калган гомерне,
Тыныч яшәргә иде.

## КАРТЛЫК ГАЛӘМӘТЛӘРЕ

Картаюның иң мөһиме
Яшьтә түгел, ул башта.
Яшәү шарты бик хөрт булса,
Мәңге яшәми таш та.

Башы таза йөз яшәрләр,
Җырлап-җырлап биилләр.
Чирле-чорлы картайганнар,
Таяк сөйрәп йөриләр.

Башта шаулый кара урман,
Ташкын тавы ике колакта.
Аяклар да бик шәп тыңламыйлар,
Эләккәннәр гүя коллыкка.

Кешеләр дә хәзер нык үзгәрде,
Аңлатмыйлар алар сүзләрен.
Кат-кат сорап булмый, кыенсынам,
Акайталар алар күзләрен.

Постельләр дә бик нык тараялар,
Ике кешене булмый сыйдырып.
Яратамның «Я» хәрефен әйтсәң,
Җибәрәләр сине сызырып.

Картлык шулай нигә мәрхәмәтсез,
Шыксыз хорафатлар килеп юл ала,
«Любовь»ның да «Л» хәрефе
Әллә кая китеп югала.

Яхшыга булган киңәш тә
Тискәрегә алына,
Гел яхшылыкны өмет итсәң,
Начардан да колак кагыла.

Кочакларлык түгел мәхәббәтсез,
Шулай була икән картайгач.
Шыгыр-шыгыр шыксыз яфрак сыман
Чагыштырыр өчен карт агач.

Бер картайгач харап икән,
Төрле уйлар уйлыймын.
Бер эштә барып чыкмагач,
Торып гармун уйныймын.

Гармуныда бер тискәре,
Моңлы көйләрне вата.
Инде уйнамыйм дип ташласам,
Ярый хатын юата.

Узең уйна,узең жырла,
Син матур уйнатасың.
Уйнатасың, жырлатасың,
Төрле уйлар уйлатасың-ди.

Минем хатын жюри бит ул,
Суз ала аһырысын…
Салаватың читтә торсын,
Син – моңлы сандугачым.

Кәчәү кодабызны әйтәм,
Ну моңлы уйната соң.
Син дә уйнап, бер жырласаң,
Йокыдан уятасың.

Мин гармунны уйнаганда,
Кумелде сихри моңга.
Картаердай түгел идем,
Картайта икән дөнья.

Уйнап җибәрсәм гармунны,
Кутәрелә күнелләр.
Илке-салкы, шәләй-валәй,
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп тә дигәндәй,
Үтте минем гомерләр.

Һич үләсе килми икән,
Көрчекләр якынлаша,
Йөрәгемне биреп китәр идем,
Алып калучы булса.

Ата-ана, балаларга,
Теләк теләргә телим.
Үз куышкайлары булып,
Тату семьясы булса,
Бу тормышта зур җимеш.

## НӘРСӘ ГЕНӘ КИЛМИ КҮҢЕЛГӘ

Кырга чыксам кыр җилләре,
Бөдрәлиләр чәчемне.
Алга килмичә белмисең,
Ниләр күрәчәгеңне.

Өй артындагы чияне
Пешкәч үзем өзәрмен.
Тагын катырак чирләсәм,
Белмим ничек түзәрмен.

Әле бар да шөкерәнә,
Чөкелдәшеп яшибез.
Балалар гына көйләнсен,
Йөзгә кадәр яшәрбез.

Тормыш китә кире якка,
Тулып туеп сикерсәң.
Иң акыллы эт ырылдый,
Бер дә юкка җикерсәң.

Кайчагында тормыш авыр,
Бар җитмәгән җирләр дә.
Артып китсә туры килә,
Күп чак газап чигәргә.

Күлдә көймәләр чайкала,
Катырак җил искәндә.
Искән җилләр дә чепуха,
Яшьлек искә төшкәндә.

Агидел ул елга гына,
Йөзәр өчен киң бит ул.
Белеп яшәү үзе бер чор,
Гасырларга тиң бит ул.

## ЭХ, ТУГАННАР!

Эх, туганнар, туганнар!
Туганнар бездән туйганнар.
Бездән алда туганнар да
Дөнъялыкны куйганнар.

Эх, туганнар, сезгә әйтәм,
Бергә ашыйк ашларны,
Дөнъялыкта бозыклык куп,
Шуннан саклыйк башларны.

Җитмәүчелек җитәр әле,
Артып та калыр әле.
Фани дөнъяның маллары,
Дөнъяда кала бары.

Туганнар өчен изге йорт,
Була ана карыны.
Туганнар бердәм булганда,
Була дөнъя байлыгы.

Туганнарым, сезгә әйтәм,
Бергә ашыйк ашларны.
Тирә-якта явызлар куп,
Берүк саклыйк башларны.

Ак куянның каралары,
Кышка каршы агара.
Замана чыбыркысы тисә,
Кара чәчләр агара.

Туганнар да таза чакта
Теләп сөйләшә иде.
Ара-тирә кайчагында
Кунакка дәшә иде.

Туганнарның була икән
Акыллы, унганнары.

Байлык өчен киң юл ачып,
Хыялый булганнары.
Үткәннәрен тиз онытып,
Туганча булмаганы.

## АХИРӘТКӘ КҮП КАЛМАДЫ

*17.01.2012 ел.*

Ахирәткә күп калмады,
Калыр якты дөнья да.
Гомер булса килеп җитәр,
Киләсе яңа ел да.

Бергә яшәү бик күп түгел,
Ни бары ярты гасыр.
Югалды сөю назлары,
Менә монысы безнең сер.

Яңа еллар кабатланыр,
Ике-өч,бәлки күберәк.
Күңел бит ул һич картаймый,
Яшәүдән туймый дүрәк.

Гайбәтчеләр сүзе кереп,
Бутый ике араны.
Дөреслекне аз сөйлиләр,
Күпчелеге ялганны.

Ат гомерем эшләп үтте,
Бу хәлләрне белмәдем.
Эт гомеренә башлагач,
Булды бөтен газабым.

Гомерең булса бер уйларсың,
Бармы минем гонаһым.
Бөтен бәла юашлыктан,
Үзем сизәм анысын.

Уйлар моны кем булса да
Сыкыранып, сукыранып,
Дөнья көттем тырышып.
Чир аямый, явыз икән,
Юкка чыкты тырышлык.

Ахирәткә күп калмады
Әллә бүген, әллә иртәгә.
Искә алып, хәер бирүчеләр булса,
Кирәк булыр шөкер итәргә.

Дөнья матур, тормыш әйбәт
Әти-әниле булса,
Балаларның үз башында
Уш-акыллары булса.

Туганнар миннән туйганнар
Дигән сүзнең азагы...
Кимсендерә, уйландыра,
Гарьләндерә заразы.
Нәрсә чәчтең – шуны урдың
Дигәнгә, туры килми заманы.

## ТӨШМӘДЕМ

*10.02.2012 ел.*

Язар идем баш эшләми,
Якынлаша көрчегем.
Көн-таң атса давление,
Узып китә көрчеген.

Хәзер дарулар да басмый,
Эчсәң дә, эчмәсәң дә.
Гомеркәйләр үтте инде,
Аракы эчмәсәм дә.

Рәфит кенә булсам да мин,
Бик күп эшләр эшләдем.
Юашлыгым алып узган,
Бер эштә дә пешмәдем.

Бакчадагы алма булып,
Мин кызарып пешмәдем.
Барыр юлым булды чокыр,
Шөкер әле төшмәдем.

Якты дөнья кемгә тар ул,
Гайбәтчеләр сыялмый.
Кеше чәйнәми торалмый,
Яхшыга юл куялмый.

Элеп ала, селкеп сала
Кешегә үз тузанын.
Нәрсә чәчсә – шуны урыр,
Белми нәрсә уңганын.

Китте диләр алай түгел,
Алып кына китәләр.
Дөнья кадерен белмәгәннәр,
Үзләре дә китәләр.

Минутын да бу дөньяның,
Миллионга алып булмый.
Бик үлмәскә тырышсаң да,
Әҗәлдән калып булмый.

Кабат кайтып яшәр идем,
Бер хата да эшләми.
Кабат-кабат урар идем,
Җир шаркаен чәчкәгә.

Укыганда тыңламыйлар,
Үзләре генә хаклы.
Берәр изге укыр әле,
Кул белән язган хатны.

Белмим, искә алырлармы,
Мин киткәч ахирәткә?
Эзләсәләр дә тапмаслар,
Мин булмам ахирәттә.

Шигырь язсам – укымыйлар,
Тыңламыйлар – укысам.
Укырлар да бик соң булыр,
Дөньялыктан юк булсам.

## ЭЧЕМДӘГЕ ТЫШЫМДА

Олыгайгач та кешеләргә,
Сөю хисләре кирәк.
Картайгач та сөешкәннәр,
Фани дөньяда сирәк.

Кеше белми үз-үзенең
Нигә туып, нигә үскәнен.
Көнне төнгә ялгап, тирен түгеп
Бер рәхәт күрми, дөнья көткәнен.

Кеше өметләнә, һич картаймый,
Сау-сәләмәт озак яшәргә.
Кайчак киресенчә чир аямый явыз,
Өметләрен өзә, олы яшьләрдә.

Әзмәвердәй таза ирләр дә бит,
Җиңә алмый бик күп чирләрне.
Прастатитлар, аденомнар хәзер,
Харап итә бик күп ирләрне.

Яши-яши кайчак бу дөньяда,
Кирәкмәгән сүзләр дөнья күрәләр.
Шул сүз өчен, күздә йоммаенча,
Үзеңә дә бәһа бирәләр.

## МӘХӘББӘТ

*02.02.2012 ел.*

Мәхәббәтең җоннан җиңел булса,
Җонне генә көйләп тетәләр.
Дәрт-дәрманың көчсезрәк булса,
Эндәшми дә үтеп китәләр.

Яратудан тора дөнья җебе,
Нечкәлектә түгел аның серләре.
«Мәхәббәткә маңка мешать итми» – дигән,
Дөрестер ул халык сүзләре.

Мәхәббәтең көчле булса,
Йөз чакырым эзләп барасың.
Үз җиреннән матурырак итеп,
Барган җирдә кала коралар.

"Гашыйк"- сүзен тиңлим,
"Лазер" - дигән сүзгә,
Себер сазын үтеп китә ул.
Юлсыз җирдә, асфальт юллар салып,
Айга кадәр менеп җитәләр.

Агач юнып, көрәк саплап кына,
Яраттырып булмый икән шул.
Гайбәтчеләр сүзе очлы сөңге,
Бар дөньяны бутый икән ул.

Яшәргә дип нык тырышсаң,
Карар итсәң китеп барасың.
Ярдәм сорап ятып еласаң да,
Бер ярдәмсез китеп барасың.

Мәхәббәтнең булды көчле чагы,
Юклыкны да урап узмадык.
Айлар буе кар урманда ятып,
Черкигә дә түздек, чыдадык.

Сагынганда ат та көтми идем,
Кайта идем җәяү Маныштан.
Тормышымда бәлки болай булмас иде,
Эчсәм, тартсам, эштән карышсам.

Төрле хәлләр булды, байлыклар да
Алга гына килеп тормады.
Шөкер итеп яшик, игелеген күрик,
Шатлыкларын күреп алда торганын.

## КӨТМӘГӘНДӘ

*07.10.2010 ел.*

Бердә юктан күршеләрнең
Ачуы килде безгә.
Нахактан гайбәт чыгарып,
Кара яктылар безгә.

Имеш тә без аңа каршы,
Имза салганбыз газга.
Эзләп-йөреп интекмәскә,
Яңавыл бирә газ да.

Хутың бетсә, күршең түгел,
Үз балаларың җили.
Яхшылыгың онытыла,
Ярдәм итим мин-дими.

Җиләрләр дә, бар көнкүреш,
Булды шул күршеләрдән.
Ит тә, сөт тә, су да, газ да
Алдык без кешеләрдән.

Әйтмәделәр, җикеренеп,
Аяк атлап басмаң -дип.
Татулык белән спурлык,
Яшәү өчен, башка бит.

Ходай бар ул, үзе белер,
Кемгә күпме тиярен.
Соңгы сәгатем сукканда
Риза-бәхил, исән яшәң,
Игелек күрең диярмен.

Көтмәгәндә булды бу хәл
Олылар көне иде.
Безгә шулай кадер-хөрмәт
Бетеп китәдер инде.

Баш бәрелеп – күз чыкмаган,
Бәлки дим, төзәлерләр.
Бар ялгышлык бездә булса,
Безгәдер төзәлергә.

## КАЛА ШУЛ

*18.01.2011 ел.*

Нык кыскарды яшәү җебем,
Җәл кала туган җирем.
Балаларым, туганнарым,
Күп кала әйтер сүзем.

Кимчелекләр баш калкыта
Балалар дөньясында.
Тыгылмадым, кысылмадым
Балалар семьясына.

Дөньялыкта бар шатлыкны
Балаларда күрәсең.
Тәртипсезлек чәчкә атса,
Тешең кысып түзәсең.

Безне тормыш заманында
Үчтек итеп "сикертте"
Ашау-эчү булмаганга,
Кәлҗәмәләр кикертте.

Бу заманның балалары
Ашаудан да туйдылар.
Аракыга басым ясап
Башкайларын җуйдылар.

## МИНЕМ ШИГЫРЬЛӘР

Әйтелмәгән сүзләремне
Язып куйдым, укырсыз.
Бәлки берәр искә алып,
Юк-юкта бер укырсыз.

Мин шигырьләр
Бик күп яздым,
Ничек булыр азагы.
Гомер буе шулай торыр,
Нык кагылса кадагы.

Яткан ташлар да кузгала,
Көчле давыл булганда.
Бәлки укып та карарлар,
Изгеләр тап булганда .

Минем эчтә бер ни калмый,
Төшерәмен кәгазьгә.
Әйтелмәгән сүзләремне,
Тапшырамын вәгазьгә.

## МАРС ЕРАК ҺӘМ ЯКЫН ДА

Без дә шушы дәлилләрне
Кабатларга барабыз.
Күп калмады шартлатырга,
Якынлаша арабыз.

Хәерчегә дөнья җитә,
Туя ашап, сөенә.
Байның байлыгы өелә,
Азак комга күмелә.

Җир язмышы Марс кебек
Әйләнер кызыл төскә.
Атом водород бомбасы
Аямый килеп төшсә.

Марста да чокыр-чакыр
Бер дә юктан булмаган.
Җирдән әйбәт яшәгәндә,
Үзе белеп туңмаган.

Комнан пыяла ясарлык
Домна мичләре кирәк.
Җир шарын дә саклау өчен,
Күп акыллылар кирәк.

Күз алдында бетерәләр
Колхоз,совхоз,заводны.
Көн-таң атса, хыялыйлар
Марс белән мавыкты.

Байлык җитмәүдән түгел ул,
Нәфсе шулай котыра.
Таяк була ике башлы,
Берсеннән үзе тона.

Төшеңдә күрсәң Марсны,
Җир кебек яшәп була.
Тиз уянма, озак йокла,
Югыйсә бар да юк була.

Марс турында уйлыйбыз,
Әле фотода күреп.
Бәлки гасырлар эшләрләр,
Җирне дә Марс кебек.

## ҺӘР КЕМ ҮЗЕНЧӘ

*19.01.2015 ел.*

Белеп яшәүчеләр өчәү:
Байыйлар колхоз талап.
Эчкәч кереп мине тирги,
Утырып күзгә карап.

Син, – ди – белеп яшәмисең,
Эшләгәннәрең «чепуха».
Хатының ташып ашата,
Бишәр сумкасын күтәрә,
Авыр дими бу ласа.

Нигә болар миңа кирәк,
Яшәсеннәр үзенчә.
Яманатлары чыкмасын,
Бу теләгем минемчә.

Юашка тынгылык юк ул,
Кайда гына барса да.
Ул гына гаепле була,
Бер эндәшми калса да.

## КАЛСЫН ИДЕ

*23.01.2015 ел.*

Туган чагымда булмаган
Яратышу кылларым.
Искәйләремә төшерде
Һәр яшәгән елларым.

Эшкә мавыгып үтте гомерем,
Җитмәүчелек алдады.
Хәзер заманы икенче,
Акыллылар болай аңлар,
Язылмасын калганы.

Тормыш коруның үзәге,
Бер-береңне ярату.
Гомер җебен өзә күрмәң,
Бик нык сакланып тартың.

Яшем – илле, яшәү – җилле,
Тартам тормыш арбасын.
Хәзер сиксәнем нәрсә ди,
– Бик озакка бармассың.

Фани доньядан китүе,
Ул бит түгел батырлык.
Йөзгә кызыллык китермәслек,
Калсын иде матурлык.

Искә алып сөйләгәндә,
Кемдер елап та алыр.
Әгәр файдам тигән булса,
Юк-юкта искә алыр.

Эт күрмәгәннәрне күрдек,
Моннан соң күрсәтмәсен.
Балаларым, туганнарым,
Оныкларым онытмасын,
Исләсен зурәткәсен.

Уйнап мендем гармунымны,
Хан тауының үрләрен.
Үлгәч тә уйнап ятырмын,
Тар булмаса гүрләрем.

Үзем үлсәм җан кала шул,
Уйнап калыр кеше юк.
Көн дә кайтып уйнар идем,
Аннан кайткан кеше юк.

## УЯН, ХАЛКЫМ!

*28.01.2015 ел.*

Уян, халкым! Җитмеш ел йокладык,
Арыу булган йокларлык.
Фашист калдыклары үрчеп,
Тагын бирми йокларлык.

Чүп үләне дә үрчи бит,
Тамыры калса җирдә.
Нәсел нәсебе калгандыр,
Кире кайткандыр җиргә.

Күз ачырлык булмады шул,
Дәһшәтле сугыш уты.
Явызлар качып калырлык,
Булгандыр берәр хуты.

Бу сугышның тарих бите,
Кан-яшь белән язылган.
Кемнең көче җитәр микән,
Үзгәртеп тарих язарга,
Немец-фашист ягыннан.

Әлеге яңа фашистлар,
Качып калган нәселдән.
Баласына шул сөйләгән,
Яңасына шул сеңгән.

Ике йөзле пычак булып,
Йөрегән ул сугышта.
Сугышта да кан-яшь эчми,
Качып йөрегән сугыштан.

Илен сатып герой булган,
Кызганмаган дус-ишен.
Әлеге Киев шуны күрсәтә,
Үз башына үзе җитәр,
Үлчәрләр әле көчен.

## ҮЗЕБЕЗНЕҢ НЕМЕЦЛАР

*28.01.2015 ел.*

Без күргәнне күрсәтмәсен,
Күрдек соңгы ноктасын.
Сугыш дигән сүз ишелсә,
Мең километрга качың.

Яу кырында булмасак та,
Халык ачтан кырылды.
Соңгы кабым фронт өчен,
Яу кыры өчен булды.

Җирдә калган ашлыкны,
Алдырмыйча кудылар.
Немец түгел, үз кешеләр,
Фашист кебек булдылар.

Биш-алтылап баласы бар,
Ире үлгән сугышта.
Соңгы кәҗәсеннән язып,
Барып керделәр утка.

Яудан качкан дезертирлар,
Тылда кырды халыкны.
Кулда камчы яки таяк
Буйсындырды халыкны.

Алар түгел читтән килгән,
Авылда калган ирләр.
Немец җиңсә, җиңеп кайткан,
Туганы кебек зурлар.

Балачак ул магнитофон,
Ни булса шуны яза.
Бер кайчан да онытылмас,
Күренеп торган каза.

## БУЛМАС ДИМӘ

*06.02.2015 ел.*

Башында кәпәче булса,
Хуҗасы үзе бора.
Җир шары да сансыз еллар,
Үзгәреп кенә тора.

Боз гасыры кабатлана,
Я булмаса су баса.
Колхоз бетсә чәчүлекне,
Кыргый үләннәр баса.

Җиребез айга әйләнер,
Котырганнар сугышса.
Үз туганын үзе кыра,
Дөньясы да утка очар,
Америка тырышса.

Бендер затлы Украина,
Нык оныткан үткәнен.
Иң гайрәтле немец-фашист
Җир йөзеннән дә киткәнен.

Бик тырышса да үз таягы,
Төшәр әле башына.
Америка су астыннан,
Килер аның каршына.

Җир шарын юкка чыгарыр,
Бары атом бомбасы.
Библи китапта әйтелгән –
Җирдә яшәү калмасы.

Бөтен дөнья хәрәкәттә,
Берсен-берсе үтерә.
Өченче дөнья сугышын
Якынайтып китерә.

Бер дивана басмас - димә,
Иң кирәкле ноктага.
Я – яшәү дә, я – яшәмәү,
Менә шушы ноктада.

Байлык кына җитә бит ул,
Үзе газиз башына.
Мескен хәерче яшәр ул,
Йөреп табар ашын да.

Байлык – диләр каян керә,
Шуннан чыга.
Байлык – диләр бер айлык,

Гомере кыска булса да.
Эшләгән эше җитәрлек,
Лужковны гына алыйк.

Америка бик күп еллар
Байлыгын җыя, өя.
Килер бер көн, җыелган
байлыкка төшеп,
Юкка чыгарыр көя.

Америкага җир җитми,
Сыеша алмый иленә.
Киләчәктә баш булам дип,
Керә кеше җиренә.

## АРЫ БАРЫП БУЛЫРМЫ

*06.02.2015 ел.*

Замананы авыр диләр,
Кем күтәреп караган.
Күтәргәннәр аны әйтми,
Заманасы яраган.

Элек колхозда эшләдек,
Колхоз булды дәүләттә.
Эшләгәнгә хакын бирде,
Җитә иде дәүләттә.

Бура тулы ашлык иде,
Абзар тулы мал иде.
Ягарга утын бар иде,
Ашарына ит бар иде.

Хәзер дә була яшәргә,
Базар тулы ашарга.
Эшләренә эш кенә юк,
Авылкайда карт-корылар,
Яшьләр йөри качарга.

Ярый әле пенсия бар,
Очын-очка ялгарга.
Хуҗалыкта маллар бетә,
Көтү көтү хәлдән килми,
Кешесе юк ялларга.

Капиталист булгач рәхәт,
Көн-төн акча чутлыйбыз.
Кирәк саен кредит алып,
Вакытында түләмәсәк,
Яшәүдән дә туктыйбыз.

## БУ ХЫЯЛЫЙ ДИМӘГЕЗ

*09.02.2015 ел.*

Сиксәндәге сирәк яза,
Үз башыннан үткәнен.
Хәтере юк, тиз оныта,
Гомеренең үткәнен.

Хәтердә калганнар күп ул,
Адым саен диярлек,
Язганда да чама кирәк,
Булмасын кеше көләрлек.

Көлү түгел гайбәт табып,
Булсын ул тәнгә сихәт.
Эштән арып киткән чакта,
Булсын иде рәхәт.

Бию белән көлү бергә,
Көн күреше яшьләрнең.
Чирем бетеп, түзем җитсә,
Тагын бераз яшәрмен.

Һәр көн уянып торалсам,
Аллага шөкер димен.
Тагын бер көн алга китсәм,
Туксанга җитәм димен.

Бу акылдан язган диеп,
Көлүчеләр күп булыр.
Үзен-үзе зурга куеп,
Күп белүче юк булыр.

Күпме генә тырышсам да,
Явыз булмас Акыллы.
Якты дөньяга килгәндә,
Ходай бирә акылны.

## ЧЫН УЛ

*09.02.2015 ел.*

Сиксән яшьтә шигырь язып,
Бәлки шагыйрь булырмын.
Бар язганны җыеп барсаң,
Чүп савыты тулырлык.

Мин язганнар – барсы да сер,
Саклаактар сейфта.
Хатынның көйсез сүзләре,
Тияләр шул кәефкә.

Якты дөнья бик кызык ул,
Бар нәрсә дә үлчәүле.
Мәхәббәт көчең булмаса,
Яратмаслар үлсәң дә.

Мәхәббәт таулар күчерә,
Кайчак агу эчерә.
Чит илләрдә бер ни түгел,
Сөю диңгез күчерә.

Мин язганны сынап караң,
Сиксәнең килеп җиткәч.
Яшем олы, күңелем яшь,
Кулдан бер ни дә килми,
Көрчеккә килеп җиткәч.

Аллар да булалмадык,
Гөлләр дә булалмадык.
Заманасы шулай иде,
Шагыйрьләр булалмадык.

## ЯРАТЫШЫП ТОРГАННАРГА

*23.02.2015 ел.*

Яратышып торганнарга
Ялгызлык кыендыр ул.
Бер-берсеннән җиләгәнгә,
Бу дөньяда кыендыр шул.

Күгәрченнәр килерләрме,
Безнең авыл түренә?
Әйбәт күңелле картлар да,
Тыштан ямьсез күренә.

Якты дөньяның минуты
Алтын тауга биргесез.
Бергә чакларның кадерен
Ялгыз калмый белмәссез.

Ул вакытта сөйләшергә,
Теләсәгез дә булмас.
Алдыңа төшкән көмеш ул,
Кат-кат дөньяга тумас.

Чакыру кәгазе килсә,
Озак көтеп тормаслар.
Мәңгегә шунда яшә дип,
Мавзолейга куймаслар.

Маршрут бар – ерак түгел,
Урын булса уярга.
Мәңгелеккә саубуллашып,
Шунда итеп куярлар.

Ялгызаклар зар җылыйлар,
Ялгыз калу кыен – диеп.
Сиксәндә дә тере булса,
Парлап бергә – яшәү бит.

Мондый хәлләр булмас диеп,
Ышанмаслар язганга.
Күз күрмәсә, баш уйламас,
Шигырь итеп язарга.

Сыңар канатлы кош очмай,
Тик утыра моңаеп.
Кешеләрнең дә гомере,
Үтә шулай саргаеп.

Нигә кадеркәйләре юк микән,
Парлап тормыш корганда.
Мәңге шулай булыр дибез.
Тормыш тыныч булганда.

## КИБӘК БАШ

*24.02.2015 ел.*

Тегермән ташын кузгатып,
Эшкә кушуы кыен.
Бер кузгалса исәбе юк,
Әйләнеп онын кою.

Дөньякайны төзү түгел, ул каеру,
Америка моңа мисал.
Көн-таң атса, кайбер илне
Бомбага тотып тору.

Украина бендерлары
Саттылар бит үз илен.
Америка корал ташый,
Болар кыра үз җирен.

Заман ахыры җитәдер,
Туеп сикерде халык.
Кайда карама террорист,
Шартлата бомба салып.

## МӘҢГЕЛЕК ХӘТИРӘЛӘР

*08.03.2015 ел.*

Дөнья хәлләре төрлечә,
Бер әйләнә, бер баса.
Без дә болай булмас идек
Илдә сугыш булмаса.

Язгы ташу көчле булса,
Җимерә ул ярларны.
Гөрләп торган тормыш бетә,
Килсә дошман яулары.

Авылда халык кырылды,
Тимәсә дә пулялар.
Җыер ризыгы булмагач,
Кибеп-корып үләләр.

Ягар утыны булмагач,
Почмаксыз калды өйләр.
Безнең буын да югалса,
Без күргәнне кем сөйләр.

Ат та булдык, эт тә булдык,
Койрык кына чыкмады.
Җирдә кычыткан калмады,
Ашап беттек чыкканын.

Ничек кирәк – исән калды,
Гомерләре булганы.
Әле тагын баш күтәрә,
Фашист яклы булганы.

Кан-яшь бергә елга булып
Акты сугыш кырында.
Дөнья халкын исәпләсәң,
Кырык миллион кырылды.

Илен сатып сугышмыйча,
Урын тапты чит илдә.
Туган җирен җимерергә
Кайттылар кире илгә.

Патша заманында качкан,
Чит илләрдә тамыр җәеп.
Тарих битләрен үзгәртә,
Булмаган нәрсәләргә.

Искә төшкәннәр язылды,
Ак кәгазь битләренә.
Бар күргәннәрем язылды,
Сыр булып битләремә.

Хәзергеләр немец түгел,
Үз туганнары дошман.
Төзелгәннәрне җимерә,
Уйласам, язам уштан.

Чит илләргә тимер ташый,
Өйдә калак калмады.
Бөтен җиргә читләр басса,
Аңлашыла калганы.

## НИЧЕКТӘ

*18.03.2015 ел.*

Нәрсә соң ул – күңел тартмау,
Яратудан читләшү.
Яратмагач якын бармау,
Мәңгелеккә хитлашу.

Сөйләшергә күңел тартмый,
Һәр бер сүзе ваемсыз.
Күтәрелеп тә карамыйм,
Абау алла – ягымсыз.

Эндәшкәндә дә эндәшмим,
Яратканым булмагач.
Гомеркәемне уздырдым,
Башка чарам булмагач.

Һәр заманның үз вакыты,
Чәчкә ата гөлләр дә.
Гомеркәем үтте инде,
Бер нәрсә юк тиңнәргә.

Рәхмәтләремнең чиге юк,
Ул ашата-эчерә.
Башка төрле тәрбия дә,
Кирәк икән кешегә.

Үзгәртергә соң шул инде,
Килеп җиттек көрчеккә.
Калган гомерне яшәрбез,
Әгәр булса - ничек тә.

Туып булмый шул яңадан,
Төзәтергә хатаны.
Узып баргандә тоталсаң,
Өйрәтер идең аны.

Күңелләрне дәртләндерә,
Йомшак ягымлы сүзләр.
Хатынын яратмаган ирләр,
Исәңкерәп йөриләр.

Ерткычлар да ияләшә,
Башын сыйпап торганда.
Ир затлары ерткыч була,
Гел акырып торганда.

Кеше белсен үз урынын,
Чама белән яшәсен.
Артып киткән һәрбер нәрсә,
Һәркем белә нишләсен.

Усаллыкның да урыны,
Бары сугышта гына.
Берсе уйлап юл куймаса,
Мөгез чыга, бары сугышса гына.

## ЯВЫЗЛЫК УЛ

*18.03.2015 ел.*

Кемнәр күрде явызлыкның
Һәр чак алда барганын.
Бәлки үзе сизми калыр,
Кинәт артта калганын.

Явызның авызы зур шул,
Йота бик күп әйберне.
Дөньялыкта шунсы бар,
Йота алмый каберне.

Бернигә дә тиңләп булмый,
Бергә корган гаиләне.
Явызның колагы читтә,
Таркатырга дөньяны.

Каты башлы ат та була,
Бирешмәгән тартуга.
Әллә ни зур көч кирәкми,
Дөньяны таркатырга.

Бүген көнүзәк мәсьәлә,
Сакларга яулаганны.
Киләчәктә бәлки булмас,
Көч белән даулаганы.

Җитмеш ел ул-җиде көндәй,
Сизелмәде яшәгән.
Киләчәкнең төп язмышы
Тора хәзер яшьләрдән.

Америка континенты,
Кырмыска куләвендә.
Дөньяга бирми тынгылык
Снаряд гүләве дә.

Кулы кычыткан түзәлми,
Игәү белән «шоркает».
Америка күңел ача,
Тыныч җирдә кан коеп.

Халык телендә мәкаль бар,
Ни чәчсә – шуны урыр.
Кып-кызыл чәчкәләр аткач,
Җимешен үзе күрер.

Җир шарында хуҗа булу,
Теләге алып узган.
Ут белән озак шаярсаң,
Каза күрерсең туздан.

Атомны да кулландылар,
Японнар да саклана.
Инде үземә төшәр-дип,
Төрле яклап саклана.

Таяк та бит ике башлы,
Юан башы сукмасын.
Әлегә яшәп була,
Берүк сугыш чыкмасын.

Сугыш чыкса герой булмас,
Калыр дөнья тырпаеп.
Дүртенче сугыш булганчы,
Җир дә бетер картаеп.

## ТАҢ ҖЫРЫ

*23.03.2015 ел.*

Таң алдыннан берәү җырлый
Үзәкләрне өздереп.
Таң әтәчкәйләре уятты
Төшләремне бүлдереп.

Таң атканда, бу төштә ул,
Уянмыйча тыңладым.
Сүзләре дә, моңнары да
Өзде күңел кылларын.

Бу, могҗиза, - моң агыла
Үзәккәйләрне өзеп.
Уянгач уйланып ятам,
Үксеп елаудан түзеп.

Гомеремдә дә онтылмас,
Төштә моң агылганы.
Бер куплеты истә калды,
Онытылды калганы.

Гомеремдә үткән еллар,
Төштә кебек булдылар.
Яшьлегемнең ал чәчкәсе,
Саргаеп коелдылар.

Үткәннәрем бераз ял бирделәр,
Картлыгыма юллар салганда.
Бәгерләрне өзеп, тагын төшкә керде,
Ахирәткә бик аз калганда.

## МАЙ ҖИТӘ

*26.03.2015 ел.*

Һәрбер елның май айкае,
Чәчкәләргә күмелә.
Май аенда без кавыштык,
Чын яшь өсти күңелгә.

Илле ике - урта түгел,
Йөз ягына сыгылды.
Күңелдә булган уйлар да,
Бик күп булгандыр инде.

Гомеремнең һәрбер таңы
Чәчкәгә йомарланды.
Явызлар гына көнләшеп
Шуларны күрә алмады.

Сукайларга сусаганда
Иң кадерлесе чишмә.
Эчеңдәге серләреңне
Дусларыңа да чишмә.

Алдыңа килгән бәхетне
Кадерләп тот, кош кебек.
Исеңә төшәр сагынсаң,
Йокыңдагы төш кебек.

Күңел яшь ул сиксәндә дә,
Сөелүдән бизмәгән.
Бөтен көчем эштә булды,
Бер нәмә дә сизмәгән.

Яшәвемә үкенмимен,
Бар да шулай яшәми.
Рәхмәт яусын аллаһыга,
Бер гасыр ук яшәлми.

## ЯРЫЙ ТӨШ БАР

*01.04.2015 ел.*

Ярый төш бар матур яшәү өчен,
Өндә юклар төштә күренә.
Тормыш өзсә мәхәббәт җепләрен,
Чын мәхәббәт төштә үрелә.

Өмет өзелсә дә яшәү өчен,
Өметсезлек төштә сүрелә.
Ходай язган язмышлар да,
Төш аркылы өндә күренә.

Гасырлар аркылы атлыйсың,
Төштә җиңел атлавы.
Уйламаган җирдән,
Тормыш юкка чыга,
Өндә бит ул тормыш катлаулы.

Өндәге ямьсез сүзләр,
Төшкәйләрдә матур ишелә.
Озакламый шунда күчер әле,
Дөньякайдан минем ишеләр.

## КАРТЛЫК

*04.04.2015 ел.*

Картлык кыңгыраулы түгел,
Мыштым гына йөри күзәтеп,
Китәр җирдән кабат тереләсең,
Картлык тота, каптың - дип әйтеп.

Бирсен ходай, шатлык белән картлык,
Сыкыранып гомер үтмәсен.
Һәрбер көнең затлы җимеш бирсен,
Бушка гына үтеп китмәсен.

Синнән соң да сөйләр сүзләр калсын,
Онытылып берүк калмасын.
Кабер сукмакларын чүп басмасын,
Әче телле явыз дошманнар да,
Чүп түгәргә шунда бармасын.

Ай-кояш та кайчак комачаулый,
Теләгәнгә тормыш көтәргә.
Ата-анасын да бала-чага кайчак,
«Мешать» итсә, читкә этәрә.

Алтын туйлар үтте,
Гомер тагын бардыр.
Балакайлар өлге алсыннар,
Үзе утырткан җиләк-җимешләрен,
Түкми-чәчми җыеп алсыннар.

Килер көннәр ямьле,
Ашау тәмле булсын,
Үткән гомер кабатланмасын.
Очар кошлар кебек ракеталар,
Явызлардан канатланмасын.

Коръән китабының һәрбер сүзе,
Уйлар өчен сырлап язылган.
Кырык көнлек оҗмах көннәре дә,
Тереклекнең яшәү тарихына,
Кабатланып шуңа кагылган.

Галимнәр дә хәзер бәян итә,
Җир йөзендә яшәү бетәрен.
Кешеләрнең шулай нык тырышып,
Үз башына үзе җитәрен.

Хуҗаның да сүзе дөрес,
Үз ботагын үзе кискәне.
Өметләнә хәзер бик күп байлар
Исән калу өчен,
Айга гына менеп киткәнне.

Миллиардерлар күзаллыйлар,
Җир шарының боздай катырын.
Еллар үткәч җирдә яшәү була,
Айдан тагын пәйгамбәрләр булып
җиргә кайтырын.

## **ХЫЯЛЫЙ ДИМӘ**

*15.04.2015 ел.*

Кеше туа озак яшәр өчен,
Яши-яши китеп бара алмаенча әҗерен.
Гомер буе үзе байлык җыя,
Күрмәенче шуның кадерен.

Утлар-сулар кичә, нык тырыша,
Үз кулында тота дөньяны.
Нык тутырган һава шары кебек,
Чыдай алмый шартлый булганы.

Америка моңа дәлил булыр,
Тынгы белми айкый җир шарын.
Берчак килеп, ике йорты юкка чыкты,
Шуннан белде дошманы барын.

Гомер буе сугыш күрмәгәннән,
Шашып китә адәм баласы.
Табигатнең газиз җәзасыннан,
Юкка чыгар бөтен каласы.

Сугыш афәтләре күрмәгән
Чыдашалмый, тәмам котыра.
Айны, Марсны да әсир итеп,
Шунда яшәү өчен, киләчәккә
Бик күп итеп планнар кора.

Убыр туймас канат куеп очар,
Кабер балчыгын да ашар ул.
Җирнең өскә түгеләчәк байлыгын да,
Тәмәм бетерер дә качар ул.

Йөзяшәрләр йөз-йөз яшәсә дә,
Яшәвеннән барыбер туймас.
Үзе белән яшәүчеләр булса,
Җир йөзендә уңайлык куймас.

## ЯРАЛАМА ТЕЛ БЕЛӘН

*29.04.2015 ел.*

Кадерле башлар яшиләр,
Яратышып, сөелеп.
Гомеркәйләре дә үтә,
Пар килгәнгә сөенеп.

Ике сыңар пар килмәсә,
Яратмый күңел тартып.
Йөзгә кадәр яшәсә дә,
Эндәшми ул ”карт” диеп.

Әче булса да борычны
Тәмләр өчен салалар.
Кадер-хөрмәтләр күрсәтсен
Үзебезнең балалар.

Пар канатсыз кош очалмый,
Тырышса да очарга.
Картайсаң дә күңел яшь ул,
Һаман тели кочарга.

Гүрдә булмый тән җылысы,
Бергә чактагы кебек.
Кадерен белгән кешегә,
Өстәлдәге ашкайлар да,
Оҗмах ашлары кебек.

Тауга карасаң тау биек,
Язмышка буйсынып яшик.
Аккан сулар кире кайтмый,
Үткән гомергә үкенмик.

Бөтен эшкә тел гәепле,
Ярлама тел белән.
Кискән яра тиз төзәлә,
Тел ярасын алып китә,
Йөрәкләр үзе белән.

Олы юлга бик чыкмыйлар,
Бер зур йомыш төшмәсә.
Кеше хәлен кеше белми,
Үз башына төшмәсә.

Тальянымны уйнадым,
Үзем белгән көйләргә.
Үзем уйнап җырлаганым,
Калыр сагынып сөйләргә.

Иртән торсам – бер сөенәм,
Бүген тагын яшим дип.
Белгән изге теләкләрне
Балаларга телим, миннән соң да
Берүк бергә яшәң - дип.

Берүк илкәйләр тыныч булсын,
Сугыш-фәлән чыкмасын.
Сугыш теләп ажгырганнар
Гомерләрен чутласын.

Акка кара да ягалар,
Төзәлмичә яралар.
Алда нәрсә барын белми,
Корал тотып баралар.

## КҮҢЕЛДӘ КАЛГАН ЯРА

*02.05.2015 ел.*

Искә алып җиңү данын,
Җитмеш елын котлыйбыз.
Кан-яшь белән яулаганны,
Нигә истә тотмыйбыз.

Без түгел ул онытучы,
Башка ил бандерлары.
Немец яклы сугышучы,
Дошманның кайберләре.

Яңа буын, яңа дошман,
Дошманның калдыклары.
Немец чәчкән орлыклары,
Саклаган сандыклары.

Польша, Литва, Украина
Утка очарлар иде.
Краковка җир йөзенә,
Күктән төшердәй иде.

Үз башларына булмасмы,
Артык чорсыз тырышып.
Ходайдан да курыкмайлар,
Бер өзлексез орышып.

Туган җирен, илен саклап,
Утыз миллион кан койды.
Төзәлмәгән яралар күп,
Үткән гомер онтылмый.
Ятим-җәбер күп тойды.

Бала чакта без кичердек
Ялангачлык, ачлыкны.
Егермегә җиткәнче дә,
Күрмәенчә ашлыкны.

Басуларда җыя идек
Төшеп калган башакны.
Чыбык-чабык ташый идек,
Җылытырга ятакны.

Тимер мичтә бәрәңгене
Ябыштырып пешердек.
Кайчакта күзләр яшьләнә,
Үткәннәрне искә төшереп.

Өйдә бозау, бәрәннәр дә, балалар да,
Шыгырдап тора өйдә.
Әти-әниләр гел эштә,
Төнлә кайталар өйгә.

Бу кадәрле афәтләрне
Күрмәсәк иде бүтән.
Бездән алдагы буын да
Рәхәт күреп яшәмәгән,
Сөйләгәннәре онтылды,
Күргәннәре дә күптән.

Һәр ашның да тәме була,
Замананың да шулай.
Ач булсак та кичләр ямьле,
Гармун моңына кушылып,
Язгы сулар да шаулай.

## ОЧЛАНМАГАН ЭШЛӘРЕМ

*07.06.2015 ел.*

Нәрсә генә эшләсәм дә,
Барып җитми очына.
Җитмәгәннәрен уйласам,
Кан басымым очына.

Кое казып газапландык,
Кольцосы юк төбендә.
Әллә шуннан, белмим нидән
Суы комлы күренә.

Өй түбәсе калай булды,
Эшләгәне «отлично».
Фронтоны ябылмады,
Сөйләшкән идек «лично».

Карбазларны да казыттым,
Ярамады гәмәлгә.
Әйбер-фәлән куеп булмый,
Су керә дә гел ләмдә.

Әле гаражлар эшләдек,
Эшләнгәннәре әйбәт.
Тагын эшлисе «навалом»,
Минем җитми шул гайрәт.

Балаларга әйтү кыен,
Калган эшне эшләргә.
Көн-төн уйлыйм, азагы юк,
Белмим нәрсә эшләргә.

Тормышка ашты күбесе,
Теләгән теләкләрем.
Таякны да тота алмыйм,
Авырта беләкләрем.

Безгә хәзер күп кирәкми,
Хәтта артык булганы.
Кадерен белеп торсыннар,
Бездән торып калганны.

Үзең тапмаган кадерсез,
Тәмсез була ашлар да.
Ата-баба нигезләрен
Теләмәдем ташларга.

Артистлар да белеп әйтә,
Үлгәч герой булалар.
Мин дә герой булмасам да,
Искә алып сөйләрләр.

Тырышканым игелеккә
Булсын балаларыма.
Бәлки әле ярап куер
Миннән калганнары да.

## ТИРӘН ТАМЫРЛЫ ГАЗАП

*14.09.2015 ел.*

Үткән, яшәлгән гомергә,
Утырасың шак катып.
Бер картайгач көне дә ел,
Уйландыра тик ятып.

Үзең киткәч калса иде,
Файдасы тиярдәй эш.
Балаларның да тормышы
Артык булсын күп өлеш.

Авылкаемның тарихын
Язар кеше булырмы?
Данис язды китап итеп
Исәнбай авыл тарихын,
Гомередә озын булсын,
Сызламасын куллары.

Күренекле шәхесләр дә
Булдылар заманында.
Рафаэль Галиев та,
Әкълимә апа Саяпова,
Рәфкат Раимовлар (монысы хәзрәт улы)

Фоат Раимов (1комсорг)
Без белмәгән укытучы, табиблар,
Авыл өчен җан кызганмый
Хезмәт иткән Гыйлим агай,
Хабибовлар күпләр алар,
Искә төшерсәң әгәр.

## ЯХШЫЛЫК ОНЫТЫЛЫР ИДЕ

*20.09.2015 ел.*

Үткәннәр калсын таш булып,
Бүтән алга килмәсен.
Барында күреп яшәдек,
Берүк яшьләр күрмәсен.

Арба, чана кулдан төшми,
Еллар буе сөйрәдек.
Йөрәкләрдә кутыр калды,
Бер өзлексез сөйләрлек.

Кояш батып, ай калыккач
Китәбез урманнарга.
Лесниклар куып кайтара
Бик мыштым барганда да.

Кулдан балтакайны алып
Тураклыйлар чананы.
Елый-елый кайтканнар бар,
Онытылмый шул чагы.

Өй бәләкәй, тезмә сәке,
Идәндә бер тимер мич.
Бишле лампакай яктырта
Өй эчкәен көн дә кич.

Яз көнендә чабатага,
«Күтәрмәләр» тагабыз.
Лычма су булып кайтабыз,
Киптерергә салам бөтереп,
Көлтә бәйләп, мичкәйләргә ягабыз.

Җан асырап язга чыксак,
Җиркәйләр дә яшәрә.
Бер яфраккайда калдырмый
Ашыйбыз, тырышабыз яшәргә.

## МИН БЕЛГӘНЕ

*16.09.2015 ел.*

Авылларга да ходаем
Гомер биргән яшәргә.
Авыл яшәүдән туктагач
Тарихы калсын яшәргә.

Данис язган китап итеп
Исәнбайның тарихын.
Иренмәгән, ярып салган
Үткәннәрнең барысын.

Үткән хыялым котырта
Тарих язарга мине.
Авыл үзе калмаса да,
Тарихы калсын иде.

Әле йөз еллар үтмәде,
Гөрләп торды авылым.
Садиклары, мәктәпләре,
Гөрләп торды, киләчәге авылның.

Ике катлы мәктәп иде,
Хәзер таш мәктәп инде.
Параллель класста укыдык,
Утыз бишләп бала идек,
Икешәр смена белән.

Районыбызда ике клуб,
Ижбулды белән Карман.
Пьеса куеп данга менгән
Чаклар да истә калган.

Колхозның да шәп чаклары,
Ит, сөт, ашлык тапшырды.
Председатель олы Гәрәй булган чакта,
Көнкүреш тә яхшырды.

Мәчетләр дә икәү булган,
Мәдрәсәсе дә булган.
Укымышлылар да чыккан
Ижбулды авылыннан.

Бер мәчетне беләм әле,
Клуб итеп тордылар.
Сәхнә эшләп театрлар,
Концерт куеп,
Шунда уйнап тордылар.

Безнең абый Гыйлемхан да,
Сафин Харис, Акрамнар...
Бик күп иде яшь җилкәннәр,
Заманында халык өчен,
Активистлар булдылар.

## ЭЧТӘЛЕК

Без яшь чакта ........................................ 3
Авылым чишмәләре........................................ 4
Гармун алдым кулыма........................................ 5
Язмыш........................................ 6
Җырлыйк әле........................................ 8
Гаҗәпләнәм үземә........................................ 9
Уйла, халкым........................................ 11
Шулай да була........................................ 12
Уйландыра икән ул........................................ 13
Төшерәмен исемә........................................ 14
Тормыш мәктәбе........................................ 16
Фәрит дус!!! ........................................ 17
Кирәге чыкса........................................ 18
Урак чүкеч бәете........................................ 19
Хыялый........................................ 21
Эх, замана!........................................ 22
Әйтим әле, эчемдәге тышымда........................................ 24
Тарихта бер мизгел........................................ 26
Ил язмышы........................................ 27
Сыкрый картлар йөрәге........................................ 28
Түрәләргә........................................ 34
Сине уйласам........................................ 34
Аңлашылмый........................................ 35
Уйланырга урын бар........................................ 36
Гәепләмә........................................ 37
Картлык яшен күрмәенчә ........................................ 38
Төтен исе........................................ 39
Әй, сез! ........................................ 40
Чукыма........................................ 40
Шуны бел........................................ 41
Алтын туй........................................ 43
Алтын туйга багышлап........................................ 43
Әйтер сүзем........................................ 44
Хәсинәнең туган көне ........................................ 45
Нәзһәткә 70 яшь........................................ 46
Туган көнең белән........................................ 46
Хәсинәгә туган көн белән........................................ 47

Уйна син Тальяныңны........................................................ 48
Туй көненә багышлап........................................................ 48
Актуаль мәсьәлә........................................................ 49
Эх, балалар!........................................................ 51
Картлык галәмәтләре........................................................ 53
Нәрсә генә килми күңелгә........................................................ 55
Эх, туганнар!........................................................ 56
Ахирәткә күп калмады........................................................ 57
Төшмәдем........................................................ 58
Эчемдәге тышымда........................................................ 60
Мәхәббәт........................................................ 60
Көтмәгәндә ........................................................ 62
Кала шул ........................................................ 63
Минем шигырьләр........................................................ 64
Марс ерак һәм якын да........................................................ 64
Һәр кем үзенчә........................................................ 65
Калсын иде........................................................ 66
Уян, халкым!........................................................ 67
Үзебезнең немецлар........................................................ 68
Булмас димә........................................................ 69
Ары барып булыр мы........................................................ 71
Бу хыялый димәгез........................................................ 72
Чын ул........................................................ 73
Яратышып торганнарга........................................................ 74
Кибәк баш........................................................ 75
Мәңгелек хәтирәләр........................................................ 76
Ничектә........................................................ 77
Явызлык ул........................................................ 79
Таң жыры........................................................ 81
Май җитә........................................................ 82
Ярый төш бар........................................................ 83
Картлык........................................................ 83
Хыялый димә........................................................ 85
Яралама тел белән........................................................ 86
Күңелдә калган яра........................................................ 87
Очланмаган эшләрем........................................................ 89
Тирән тамырлы газап........................................................ 91
Яхшылык онытылыр иде........................................................ 92
Мин белгәне........................................................ 93